Фәрит Мөхәммәтшин:
«Хакимият гомерлеккә бирелми. Иң мөһиме – кеше булып калу»

Татарстанның Дәүләт Советы рәисе сәясәт, хакимият, гаилә һәм тормыш кыйммәтләре турында

6-7 БИТ

Авыл туризмы: бар да, юк та

Соңгы елларда авыл туризмы турында күп сөйләшәбез. Аны билгеле бер системага салырга, авыл территорияләренең комплекслы туристик продуктын таныту өчен интерактив карта төзергә, аерым сайт булдырырга, бу эш белән шөгыльләнүчеләргә ярдәм күрсәтергә кирәк дибез. Тик нишләптер шул сүздән ары уза алмыйбыз.

10-11 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Пәнҗешәмбе | 18.05.2017 | № 52 (5814) www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

«ГАЕПЛЕНЕ АЛЛАҺЫ ГЫНА БЕЛӘ»

«ШК» журналисты кабер ташлары җимерелгән Бәчек зиратында булды

Май бәйрәмнәре алдыннан, Яшел Үзән районының Бәчек авылы зиратында кабер ташларын җимергәннәр, дигән хәбәр барыбызны да тетрәндергән иде. Халык өмә ясап каберлекләрне рәткә китерергә дә өлгермәде – тагын шул хәл. Бәчек зиратында 14 май көнне 113 кабер ташын аударганнар. Баксаң, зират тарихында мондый вәхшилек инде дүртенче тапкыр кабатлана икән.

Фото: Максим Платонов/realnoevremya.ru

5 БИТ

П2430 Атналык (пәнҗешәмбе)

1 айга 69 сум 31 тиен
3 айга 207 сум 93 тиен
6 айга 415 сум 86 тиен

Ташламалы бәядән язылу!

11-21 май, 2017
Абунәче декадасы

П2395 Көндәлек (сишәмбе, пәнҗешәмбе, җомга)

142 сум 38 тиен 1 айга
427 сум 14 тиен 3 айга
854 сум 28 тиен 6 айга

Реклама

РЕСПУБЛИКАДА

АКСУБАЙ

Яңа Ибрай авылында тарихи вакыйга булган – Бөек Ватан сугышы ветераны генерал-майор Алмас Әдһәмовка һәйкәл ачылган. Бу легендар шәхес 1945 елда Кызыл мәйданда Җиңү парадында катнашкан. Җиңүнең 50, 55 еллыгын да Кызыл мәйданда каршыларга насыйп булган аңа. Һәйкәлне куюда авыл халкы да ярдәм күрсәткән. Бюстның авторы – Татарстанның атказанган сынчысы Мәхмүт Гасыймов.

АЗНАКАЙ

Таллы Буләк авылында кыр механизаторларына «Юлдаш» агитбригадасы язгы чәчү чорында концерт бүләк иткән. Ялны эш белән аралаштыру хезмәткә дәрт өсти, ди кыр батырлары.

ӘГЕРҖЕ

Кодаш авылында яшәүче Рәхимә Әхмәтшинага 100 яшь тулган. Юбилярны котларга килгән район хакимияте башлыгы тыл ветеранына Россия һәм Татарстан Президентларының котлау открыткаларын да тапшырган.

МАМАДЫШ

Мамадыш районында ике терлекчелек фермасы төзергә җыеналар. Бер комплекста төзелеш эшләре инде башланган. Ул 3600 баш терлеккә исәпләнгән. Икенчесе ун мең сыер сыешлы булачак. Сүз уңаеннан, Мамадышта Германиядән кайтартылган сыерлар да үрчетә башлаганнар.

ЧИРМЕШӘН

Кармыш авылында шәхси хуҗалыкларда һәр көнне уртача бер тонна йөз килограмм чамасы сөт җыела икән. Сыер асраучылар артса да, күпләр җәй көне сөткә бәя кимүдән зарлана.

ЮТАЗЫ

Кече Урыссу авылында борынгы йолаларның берсе – «Бәби туе» күрсәтелгән. Чарада бишек җырлары, мәкальләр, сынамышлар, табышмаклар, мөнәҗәтләр яңгыраган. Авыл халкының кул эшләреннән күргәзмә дә оештырылган.

Яңалыклар район газеталары сайтларыннан алынды

Кош гриппы Казанга килеп җитте

Лаеш кошчылык комплексында тавыкларда H5 штаммлы вирус табылу турында узган санда язган идек. Комплекска кош гриппыннан килгән зыян 100 миллион сумнан артык дип исәпләнелә. 447 мең баш тавыкны яндырачаклар дип язган идек.

Эльвира МОЗАФФАР

instagram.com

Бу хәлдән соң республиканың башка районнарында да тавыкларны тикшерә башладылар. Нәтиҗәдә Татарстанда тагын берничә урында – Нурлат, Балык Бистәсе, Ютазы районнарында шәхси хуҗалыкларда кош гриппы вирусы ачыкланган. Чир Казанга да килеп җиткән. Дәрвишләр бистәсендә бер шәхси хуҗалыкта 500ләп тавык, үрдәк кырылган. Президент Рөстәм Миңнеханов карары белән, бу территорияләрдә 21 көнлек карантин игълан ителде. Дәрвишләр бистәсе тирәсендәге карантин зонасына эләккән Яңа Савин, Авиатөзелеш, Биектау районындагы хуҗалыктагы кошларны да ныклап тикшерәчәкләр, тавыкларга прививка ясаячаклар.

– Бернинди дә куркыныч юк. Вирус ачыкланган барлык тавыклар да Лаеш кошчылык комплексыннан сатып алынган булган. Кош-корт сатып алмыйча да булмый, хәзер сезоны бит. Бары тиешле таләпләрне генә үтәргә кирәк. Ветеринария документлары булмаган оешмалардан, санкцияләнмәгән базарлардан кош сатып алмагыз. Йорт кошларында авыру билгеләре күзәтелгәндә, шәһәр яки районның дәүләт ветеринария хезмәтенә мөрәҗәгать итәргә киңәш ителә, – ди Татарстан буенча Россельхознадзор күзәтү идарәсенең Дәүләт ветеринар күзәтчелек бүлеге җитәкчесе Идрис Гатин.

Сүз уңаеннан, Идел буе федераль округының берничә төбәгендә: Оренбург, Саратов, Пенза, Чуашия, Пермьдә 15 ноябрьгә кадәр Татарстаннан кош-корт һәм кошлар өчен азык алу тыелган, дип хәбәр итә ТАСС. Күрше төбәкләрдә дә кош гриппыннан саклану чараларын күрә башлаганнар. Чуашиядә, мәсәлән, хуҗалыкларга кош гриппы турында язылган белешмәлекләр тараталар, кошларны иминиятләштерергә киңәш итәләр. Ульяновск өлкәсендә кош сату өлкәсендә күзәтчелекне көчәйткәннәр. Кошчылык фабрикалары ябык типтагы эш режимына күчкән.

КОШ ГРИППЫ ТУРЫНДА ӨЧ СОРАУ

Кеше өчен куркынычмы?

Владимирдагы Бөтенроссия терлекчелек фәнни-тикшеренү институты уздырган лаборатор тикшерүләр буенча, Лаеш кошчылык комплексындагы тавыкларда ачыкланган H5 штаммлы вирус кеше өчен куркыныч тудырмый.

Тавыктагы вирус үрдәкләргә, казларга күчәме?

Кошларда очрый торган вирус булгач, ул казга, үрдәккә, күркәгә дә күчәргә мөмкин.

Авылда бер шәхси хуҗалыкта кош горИППы ачыкланса, бөтен кешенең тавыгын да юк итәчәкләрме?

Юк. Бары вирус ачыкланган тавыкларны гына юк итәләр. Ул урынны дезинфекцияләячәкләр. Ә күршеләргә тавыкларын күзәтеп торырга киңәш ителә, кош гриппы турында белешмәлек бирәчәкләр.

Шәһәр кәефе

РӘШИД ГЫЙЛЬФАНОВ,
отставкадагы хәрби:

– Кайбыч районында туыпүсеп, хәрби хезмәттә элеккеге СССРны урап чыга яздым мин. Брестта башланды һәм Уралда тәмамланды ул юл. Башка җирләрдә чакта туган як гел искә төшеп сагындырып тора. Шунлыктан, отставкага киткәч, Татарстаныма кайттым. Үзем белгән һәм күргән шәһәрләр арасында Ленинград матур истәлек булып калды, аның кешеләре бик зыялы. Казанга бу җитми әле. Санкт-Петербург – өлкәннәр өчен ул һаман Ленинград.



ГӨЛНАР ДӘҮЛӘТШИНА,
кибетче:

– Казанда яши башлаганыма 26 ел булды. Балтач районының Борбаш авылыннан кичә генә юлга кузгалган кебек. Мөселманнарны якынлашып килүче изге Рамазан айлары белән котлыйм! Ураза тотачак кешеләргә җиңеллек, ниятләренең кабул булуын телим. Һәр кеше исән-имин гомер кичерсен! Аллаһы боерса, үземнең дә олы хыялым бар – Хаҗ сәфәре кылырга телим.

КЛАРА ЛАЗАРЕВА,
пенсионер:

– Казан авиация институтын тәмамлагач, Красноярск краенда 20 ел эшләдем. Шушында туыпүскәч, төшләремә керә иде Казан. Шуңа да үз шәһәремә әйләнеп кайтуым белән бәхетлемен. Чит илләргә яшәргә китүчеләрне кызганам. Яшь чакта, бәлки, беркадәр читтә яшәп-эшләп алу ярыйдыр. Ләкин сагынып гомер кичерү – тормыш түгел ул. Рихард Зорге урамындагы ишегаллары шактый таушалды. Аларны төзекләндерә башласыннар иде.

РАДИЛӘ МУСИНА,
хезмәткәр:

– Камыр ризыклары пешерергә яратам. Арча районындагы Түбән Мәтәскә авылына әни янына кайтып йөрибез. Пешергәндә, әни өйрәткәннәрне төгәл үтим, ләкин әни әзерләгән ризыклар барыбер тәмлерәк. Өлкәннәргә игътибарлы булсак иде. Яшьләрнең кайберләренә шушы сыйфат җитми. Җәмәгать транспортында ачык чагыла бу. Берәр егет яки кыз өлкәннәргә урын бирсә, автобус эче балкып киткәндәй була.

АЛЕКСАНДР ОРЛОВ,
менеджер:

– Мәскәүдә яшим. Казанга дүртенче мәртәбә килүем инде. Казанны яраттым. Эш буенча командировка чыкса, Казанга үзем барыйм әле, дим. Мондагы хезмәттәшләр тырыш, алар белән эш йөртүе җиңел. Зур хыяллар, буй җитмәс максатлар белән яшимим. Үземә йөкләнгән эшне төгәл башкарырга омтылам. Казанның Бауман урамында төрле ил һәм милләт кешеләре очрый. Мәскәүнең Кызыл мәйданынннан бер дә ким түгел, билләһи.

president.tatarstan.ru

Россия ислам илләре белән мөнәсәбәтләрне ныгыта

Бу көннәрдә Грозный шәһәрендә «Россия – ислам дөньясы» стратегик күзаллау төркеме утырышы уза. Билгеле булганча, әлеге төркемне Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов җитәкли. Утырышта Россиянең мөселман илләре белән үзара икътисади хезмәттәшлеге перспективалары турында сөйләшәләр. Шулай ук чара кысаларында ислам һәм башка диннәр тәҗрибәсенә, рухи байлыкларга нигезләнеп, куркынычсызлыкка янау үсешенә каршы торуга чараларны билгеләү мәсьәләләре дә карала.

Рөстәм Миңнеханов, очрашуны ачып җибәргәндә, төркем эшчәнлегенең Россиядә ислам турында дөрес картина формалаштыруга ярдәм итүен билгеләп үтте.

– Милләтара һәм динара тынычлык – дәүләтебез нигезе. Бу безнең уникаль үзенчәлегебез, без аны саклыйбыз һәм үстерәбез. Терроризм һәм радикализм – мөселман илләренә генә түгел, ә бөтен дөньяга яный. Без тәҗрибәбез белән уртаклашырга әзер, чөнки хәзерге замандагы авырлыкларны бергәләп кенә хәл итеп була, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Ул үзенең чыгышында төркемгә яңа вәкилләр кушылуы турында хәбәр итте. Алар арасында Әзәрбайҗан, Бәхрәйн, Малайзия бар.

Рөстәм Миңнеханов ассызыклаганча, төркем эшенең өстенлекле юнәлешләренең берсе – икътисади хезмәттәшлек. Ел саен Казанда «Россия ислам дөньясы: Казансаммит» халыкара икътисади саммиты үткәрелә. Быел анда 50 илдән 1,5 меңнән артык делегат катнашырга җыена. Шулай итеп, төркем эшчәнлеге Россия базарына ислам дәүләтләреннән инвесторларны җәлеп итәргә ярдәм итә. Хәзерге вакытта, Ислам үсеш банкы белән берлектә, Россиядә ислам банкингын җайлау мәсьәләләре хәл ителә. Былтыр төркем утырышында Казанда Ислам үсеш банкы һәм Россия финанс институтлары арасында үзара килешкәнлек турында меморандум имзаланды.

Исегезгә төшерәбез: «Россия – ислам дөньясы» стратегик күзаллау төркеме 2006 елда оештырылды. 2014 елда Россия Президенты Владимир Путин төркем рәисе вазифаларын Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановка тапшырды. Татарстан Президенты рәислегендә беренче утырыш 2015 елның июнь аенда яңартылган форматта узды. Икенче утырыш 2016 елда Казанда үтте.

Күпмилләтле һәм күпконфессияле Россия өчен ислам дөньясы белән хезмәттәшлек аеруча мөһим юнәлешләрнең берсе булып тора.

Владимир ПУТИН,
Россия Президенты:

– Төркемнең алдагы утырышы Казанда узды, сезгә анда, милләтара һәм динара мөнәсәбәтләрнең нык булуы аркасында, аларның нинди шаккаткыч нәтиҗәләргә ирешүләрен үз күзләрегез белән күрү мөмкинлеге туды.

(«Россия – ислам дөньясы» стратегик күзаллау төркеме утырышына җибәргән сәламләү телеграммасыннан)

Рамзан КАДЫЙРОВ,
Чечня башлыгы:

– Без Татарстан җитәкчелегенә тиңләшергә тырышабыз. Безгә Татарстанның икътисады һәм сәясәте ошый. Яшьләребезне һичшиксез Болгар ислам академиясенә укырга җибәрәчәкбез.

Сыер ни дә, утын ни

Лениногорск районы Иске Куак авылында КАМАЗ машинасыннан сыерларны төшерү күренешен тасвирлаган видеоязма күпләрдә ризасызлык уятты.

Гадәттә, мөгезле эре терлекне күчерү өчен махсус трап кулланыла. Ә видеода терлекләрне йөк машинасыннан утын бушаткандай төшерәләр: сыерлар, бозаулар берсе өстенә берсе төшә, егылалар, торып китә алмыйлар. Социаль челтәрләрдә, бу вәхшилеккә канәгатьсезлек белдереп, фикерләрен белдерүчеләр дә булды. Эш хәтта прокуратурага барып җитте. Татарстан прокуроры Илдус Нәфыйков бу вакыйга буенча тикшерү үткәрергә йөкләгән, дип хәбәр итә «Татар-информ». Сыерларны җибәрләүче кешеләр эшләреннән азат ителгән. Агрофирманың генераль директоры урынбасары Ирек Ягъфәров, бер хайванга да зыян килмәгән, дип ышандыра.

Адел ВАФИН,
Татарстанның сәламәтлек саклау министры:

Киләсе елга мөһим бурыч – ир-атлар белән хатын-кызларның гомер озынлыгы арасындагы аерманы кыскарту. Бүген хатын-кызлар ир-атларга караганда ун елга озаграк яши. Ир-атлар өчен иң төп дошман ул – диван һәм аз хәрәкәтләнү.

САН

*Республика балалар клиник хастаханәсе матбугат үзәге хәбәр итүенчә, былтыр Татарстанда төрле имгәнүләрдән **85** бала үлгән. Аларның **64,7** проценты – малайлар. Үлемнең сәбәпләре **20** очракта суга бату белән бәйле, **18**е – юл һәлакәтләре аркасында, **9** бала биектән егылып бакыйлыкка күчкән, **13**енең үлем сәбәпләре ачыкланмаган.*

ТОП – 3

19 МАЙ көнне «Кол Шәриф» мәчете янында Казан Кремлендә сакланган ханнарның җәсәден Сөембикә манарасы янындагы мавзолейга күчереп җирләячәкләр. Әлеге ханнар тарихына багышланган 500 битлек документаль басма да әзерләнә. Казан ханнары җирләнгән мавзолейны мәдәни мирас объектлары исемлегенә кертү дә күздә тотыла. Тантаналы чарада VII Бөтенроссия татар дин әһелләре форумына килүчеләр дә катнашачак.

РОССИЯДӘ интернетта һәм телевидениедә спиртлы эчемлекләрне рекламалау тыелган. Депутатлар «Массакүләм мәгълүмат чаралары турында»гы законга да үзгәрешләр кертергә тели. Сәгать 6дан 23.00гә кадәр алкоголь кулланган күренешләрне документаль фильмнарда, гомумән, телевидениедә күрсәтмәскә тәкъдим итәләр. Бу хакта хат премьер-министр Дмитрий Медведевка юлланган.

СОЦИАЛЬ челтәрләрдә «1 июньнән ЮХИДИ хезмәткәрләре, автобус полосасыннан йөрүчеләрне теркәр өчен, җәмәгать транспортына махсус камералар куячак. Тәртип бозучыларга – 1500 сум штраф» дигән хәбәр таралган иде. Татарстанның ЮХИДИ идарәсе әлеге мәгълүматны кире кага. Дөрес, бу – автобус полосасыннан йөрергә ярый дигән сүз түгел. Тәртип бозу очракларын видеокамерасы булган һәркем төшереп, «Халык инспекторы» кушымтасына юллый ала.

КҮРШЕЛӘРДӘ

Башкортстан

Май салкын булуга карамастан, Уфа шәһәрендә инде коену сезонына әзерләнә башлаганнар. Комлыклар, гадәттәгечә, 1 июньдә ачылыр дип көтелә. Быелга Уфада 11 комлык халыкны кабул итәргә әзер. Мәйданны талпаннарга каршы препаратлар белән эшкәрткәннәр, куркынычсызлык чаралары күрелгән.

Мари Эл

Йошкар-Олада 33 яшьлек бер хатын ике ел дәвамында интернет аша чынлыкта булмаган нәселле этләрне «сатып» акча эшләгән. Хокук саклаучылар законсыз эш белән шөгыльләнүче мошенникның эзенә төшкән. Тикшерү нәтиҗәләре буенча, хатын 17 ялган эштә гаепләнелә, гомуми зыян күләме 150 мең сумнан артык. Ул яшәгән фатирдан тугыз кесә телефоны, ике ноутбук, планшет, 46 сим-карта, сигез банк картасы табылган. Хатын акчаларны наркотиклар алу өчен тоткан. Аңа карата җинаять эше ачылган.

Чуашия

Чуашия Республикасының Кызыл китабына гади бурсыкны кертергә җыеналар. Республиканың хөкүмәт комиссиясенең беренче утырышында бу фикерне барысы да хуплаганнар. Чуашиядә бурсыклар бик сирәк очрый икән. 1990 ел азагында алар бары 600ләп кенә исәпләнгән.

МАГНИТ ДАВЫЛЛАРЫ

20-25 май көннәрендә магнит давыллары көтелә. Бу көннәрдә йөрәк авырулы кешеләргә ерак юлларга чыкмаска, авыр физик эшләр эшләмәскә, бәхәсләргә кермәскә, тыныч булырга киңәш ителә. Калган көннәрдә җирнең магнит кыры тыныч.

Комсомол базарында

Халыкның ничек яшәгәнен, нәрсә белән сулаганын белим дисәң, базарга бар. Чуашиянең Урмай авылына юл Комсомол районының үзәге аша үтә. Кызыксыну үзенекен итте, базарга да кереп чыктык.

Автор фотосы

Зөлфия ХӘЛИУЛЛИНА

Иң беренче безнең күзгә ташланган әйбер капчык-капчык симәнәләр булды. Аларның күбесен безнең Татарстан авылларында үстерәләр дип тә әйтә алмыйм, һәрхәлдә, үземнең күргәнем юк. Эспарцет, судан үләне, синяк, козлятник... Сәфәрдән кайткач, кызыксынып карап чыктым. Эспарцет азык буларак та бик файдалы, ә бал алу өчен бигрәк тә уңышлы икән. Бер гектар эспарцет кырыннан бал кортлары 6 килограмм бал җыя. Башкаларының да һәркайсының үз өстенлеге бар. Орлык белән сәүдә итүче, исемен әйтергә теләмәгән абзыйдан дүрт төрле орлык сатып алдым, теләгем – үзебезнең бакчада сынап карарга. Бәяләре бер килосына 60-75 сум тирәсендә.

Суган сатучылар да бихисап. Бәясе бер килосына 60 сумнан башлана. Ә менә гөл үсентеләре бик кыйммәт кебек тоелды. Гади генә савыттагы гадәти генә гөлләргә 300-350 сум сорыйлар. Җиләк-җимеш үсентеләре дә төрледән. Азык-төлектән иң күп тәкъдим ителгәне – прәннек. Ниндие генә юк! Шулай да колакка иң ятышлысы сатучының: «Татарстан ипие, аннан башка берничек тә булмый, ипи алабыз», – дип әндәшүе булгандыр. Татарстан бренды эшли, димәк!

Бик күп ит һәм йомырка бирә торган мең ярымлык кара тавыкка хәйран калып торганнан соң, талдан үргән кәрҗин сатучы әби янына тукталдык. Әллә кәрҗин ошады, әллә әби, бәлки бәяседер, бары тик 200 сум гына тора, ничек кенә булмасын, кәрҗин машинага кереп урнашты. Бер истәлек булыр.

Банклар эше буенча эшче төркем булачак

«Татфондбанк» буенча сораулар хәзер дә тынмый. Хөкүмәт бу мәсьәләдә халыкка ярдәм итү юлларын эзли. Күптән түгел Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Мәскәүдә «Кертемнәрне иминиятләштерү агентлыгы» дәүләт корпорациясе белән генераль директоры Юрий Исаев белән күрешеп сөйләште, дип хәбәр итә Татарстан Икътисад министрлыгының матбугат үзәге. Җитәкчелек «Татфондбанк», «Интехбанк»ны ликвидацияләү хакында фикер алышкан, чара кысаларында, бу мәсьәләдә мөһим карарлар кабул ителгән.

Тиздән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте һәм кертемнәрне иминиятләштерү агентлыгы вәкилләреннән торган эшче төркем оешачак. Бу – банкларны ликвидацияләү эшләренең ачык, ялгансыз баруын күзәтү өчен дә эшләнә. Бирелгән кредиторларны иминиятләштерелгән кертемнәр реестрына кертү, милек мәсьәләләре дә хәл ителәчәк.

Вакыйгаларның үзәгендә кайнаган кредиторлар, проблеманың чишелешен күзәтеп бара алсын өчен, бу эштә үзләре дә катнашырлар дип көтелә. Кредиторлар комитеты нәкъ менә «Татфондбанк» һәм «ИнтехБанк»тан зыян күргән клиентлардан төзеләчәк. Кертемнәрне иминиятләштерү агентлыгы хезмәткәрләре, Рөстәм Миңнеханов карары белән, Татарстанда эшмәкәрләргә кагылышлы сорауларны хәл итү максатыннан оештырылган, икътисад министры Артем Здунов җитәкләгән эшлекле төркем утырышларында да катнашачак.

ФИКЕР

Хәсрәтледән хәсрәтле туса

Аксубай хастаханәсенең бала тудыру бүлегендә озак еллар эшләгән, йөзләрчә баланы якты дөньяга чыгаруда булышкан, шул сабый язмышларының төрлесен күргән Алсу сеңелнең (бертуган энемнең кызы) бераүгә сөйләгәннәре абыйсы аша миңа да килеп ирешә һәм гаҗәп уйларга салды. Әниләре ташлап калдырган балалар матбугатта күренгәләгәннән шактый күп икән. Ләкин иң гаҗәбе бу түгел, көенечебезгә, без мондый хәлләргә гаҗәпләнмибез, ияләштек тә инде. Гаҗәбе шул – әниләре ташлап китәчәк нарасыйлар үзләрен иртәгә нинди аяныч язмыш көтәсен сизенәләр: борчылалар, елыйлар, ди.

Шулай да табибә сеңелнең сүзләрендә бераз хата бардыр кебек. Бәлки ул миңа гына шундый хаталы килеп җиткәндер. Чөнки баланың үзен ташлап калдырачакларын алдан сизенүе бик ышандырмый. Бала табасы ана үз сабыен тапкан җирендә калдырып китәчәген, бу фикергә китергән сәбәпләрне йөз кат уйлыйдыр, борчыладыр бит инде ул. Шул кара, караңгы, күңелсез уйлар туачак баланың психикасына начар тәэсир итәдер һәм шунлыктан ул борчылучан, елак булып туадыр. Димәк, баланың тынычсызлануы аның киләчәкне сизенүеннән түгел, ә бәлки әнисенең үткәндәге халәтеннән. Болай фикер йөртсәк, нилектән балаларның елдан-ел көтелмәгән авырулар белән тууын, үсмерләрдә агрессивлык үсүен, җәмгыятьтә миһербансызлык, бәгырьсезлек, каты күңеллелек артуын, алдакчылык һәм ялганның тамыр җәюен әйбәтрәк аңларбыз аннары. Әй ул Рәсәй аналарының һәм ана буласы кызларның күргәннәре! Әле дә ярый ана булу, бала табу сәләтен җуеп бетермәгәннәр алар! Ул сәләтне табигать аналарга нык беркеткән, күрәсең.

Узган егерменче гасырны гына күз алдыннан уздырсак та, исләрең китәрлек бит: Ленин тарафдарларының революциясе белән башланган да, Ельцинчылар контрреволюциясе белән тәгәлләнгән. Араларында ак террор, кызыл террор, ничә сугыш, ничә ачлык-ялангачлык, иң-иң әшәке илдәшләр сугышы! Сугышуын ир-атлар сугышса, җәфасы, кайгы-хәсрәте хатын-кызларга да бит. Хәтта сугышы да аларсыз бармады, җиңүе дә аларсыз килмәде. Өстәвенә, эчүчелек дигән бәланең дә иң зур авырлыгын нәфис затлар күтәрәсе булды. СПИД та күбрәк хатын-кызлар башыннан йөри. Шул аналарның, шул кызларның алдагы көннәрдә чагыштырмача сау-сәламәт бала тудырулары да Ходай могҗизасыдыр әле. Икенче бөтендөнья сугышы дигәнебез күп илләрне каплап алган иде дә, әмма аларда тормыш тизрәк көйләнгән шул. Без аларын да күп еллар узгач кына белдек, озак вакытлар ач-ялангач яшәсәк тә, бүтәннәр хакында бихәбәр булып, үз «бәхетебезгә» кинәнеп гомер иттек.

Бер-бер гөнаһыбыз өчен Аллаһыбыз шундый җәза бирәме, патшаларыбыз шулай телиме, тормышыбыз бераз әзгә баса, көйләнәме генә дигәндә, нинди дер бер гомумхалык борчуы уйлап чыгаралар да һәммәсен әйләндереп ташлыйлар, илгә йә ачлык, йә бүтән каза китерәләр. Хәзерге яшьләр ышанмас та, карагыз инде ул Хрущевны ил тәхетеннән бәреп төшерәсе елдагы ачлык-мохтаҗлыкны! Сугыш та юк, санкцияне ишетеп тә белмибез, кризисны капиталистик илдә генә була дип укыйдык, табигатьтән дә зур бәла-каза килмәгән иде, җиребез дә киң, коры дөньяның алтыдан бер өлеше кадәр, ә без ярым ач. Хрущевның маллар өчен кукуруз чәчәргә өндәвеннән көлеп, ипине кукурузлы һәм тагын әллә ниләр кушылган он белән пешерттеләр, әле анысы да җитәрлек түгел иде. Кибетләрдә азык-төлектән диңгез кәбестәсе консервысы гына калды, бәрәңгең белән ашарга тозлы килки эләктерсәң дә шат идең. Аракыны гына чикләүсез саттылар. Ә бит ачлык дигән нәрсә иң элек әниләр җанын кимерә, чөнки балалары ачыгуын нәкъ алар беренче булып күрә. Ач һәм авыру балаларының ашарга сорап тилмерүләренә җаны өзгәләнгән ананың «ичмасам берсе үлми дә бит» дип иңрәвен сугыш азагы һәм сугыш арты елларында без дә ишеткәләп калдык әле. Без ишетмәгәннәре никадәр булгандыр. Шәһәр халкы авылныкылардан да бигрәк йөдәгәндер, мөгаен.

Ә Хрущевны урыныннан алырга әзерләнүче фетнә төркеме өчен нәкъ менә халыкның аны күралмавы, төшерелгәннән соң яклап күтәрелмәве, шул кирәк ул дуңгыз көтүчесенә дип кул селтәве хаҗәт булган. Азык-төлекнең булган кадәрен халыкка чыгармыйча складларда саклап, ясалма ачлык барлыкка китерү әнә нинди «бөек» максат белән эшләнгән икән. Төрле яктан җентекләп уйлап эш иткәннәр, чөнки Сталин тиранлыгыннан соң халыкка беркадәр иркенлек биргән, бигрәк тә авыл хуҗалыгына хакимиятнең аз-маз игътибарын юнәлткән, колхозчының кеше хокукларын торгызган ил башлыгын яклап чыгу да урынсыз булмаячак иде. Ләкин андый үрнәкләр чит илләрдә күренгәләсә дә, совет халкынамы соң гаделлекне яклап күтәрелү. Ил башындагы бер төркемнең, үзләренә ошамаган иң югары җитәкчегә үч итеп, күп миллионлы ил халкын ачлыкка, сугыштан соң котылып та җитмәгән яңа мохтаҗлыкка дучар итүе шулай ук дөнья тарихында күрелмәгән хәлдер. Хатын-кызларыбыз бу афәтне дә кичте. Ни бәрабәренә – анысы әнә алар тапкан балаларда күренә.

Бай булмасак та, тыныч-имин «торгынлык»та киләчәккә өметышаныч белән көйле генә яшәп ятканда, байлар-түрәләр, тагын бер түнтәрелеш ясап, илне дер селкетеләр дә халыкны юл читенә чыгарып ташладылар. Тагын хатыннарга бәла: балаларын гына түгел, эшсез калган ирен дә туендырасы бар аның. Кем түзә, кемдер түзә дә алмый моңа. Чөнки бүгенге ирләр дә, хатыннар да шундый ук мең хәсрәтле, мең уйлы аналардан туган кешеләр. Хәтта ил башындагылары да шундый ук аналар тудырган, шуңа күрә аларда үзебездәге кебек сәерлекләрне, холыксызлыкны күрү безне бик гаҗәпләндерми. Бүген әниләргә, әни буласы кызларга көйле, тыныч-имин тормыш тәэмин итү дәүләтнең, бөтен җәмгыятьнең иң мөһим, кичектергесез вазифасыдыр да бәлки, тик мондый уйга кайчан килербез икән соң әле без?! Гомумән, берәр килербезме? Югары мөнбәрләрдән шул хакта сүз кузгатучы берәр депутат, берәр министрны ишеткәнегез бармы? Бүгенге бер хәсрәтледән иртәгә ике хәсрәтле, аннан өч хәсрәтле туса һәм шулай дәвам итсә, йомык түгәрәктән чыга алмавыбыз да ихтимал бит.

Рәфыйк ШӘРӘФИЕВ,
Балтач районы,
Карадуган авылы.

«ГАЕПЛЕНЕ АЛЛАҺЫ ГЫНА БЕЛӘ»

«ШК» журналисты кабер ташлары җимерелгән Бәчек зиратында булды



Илдар Мөхәммәтҗанов фотолары

Май бәйрәмнәре алдыннан, Яшел Үзән районының Бәчек авылы зиратында кабер ташларын җимергәннәр, дигән хәбәр барыбызны да тетрәндергән иде. Халык өмә ясап каберлекләрне рәткә китерергә дә өлгермәде – тагын шул хәл. Бәчек зиратында 14 май көнне 113 кабер ташын аударганнар. Баксаң, зират тарихында мондый вәхшилек инде дүртенче тапкыр кабатлана икән.

Бәчек зиратында булган вәхшилек Татарстан өчен яңалык түгел. Мондый хәл берничә ел элек Казанда Горький паркы янындагы Арча зиратында булган иде. Былтыр башкаланың борынгы Яңа Татар зиратында да вандаллык кабатланды. 8 сентябрьдә анда 100ләп кабер ташын җимерделәр. Зыян күргән объектлар арасында танылган композитор Салих Сәйдәшевнең кабере дә бар иде. Кызганыч, җинаятьчеләрне ачыклый алмадылар. Шушы көннәрдә Башкортстанның Туймазы зиратында да 20гә якын кабер ташын ватканнар. Бу вакыйгага уңаеннан җинаять эше ачылган, дип хәбәр итә Башкортстанның Эчке эшләр министрлыгы.

Бәчектәге вакыйгага килгәндә, Татарстан Эчке эшләр министрлыгының матбугат үзәге хәбәр итүенчә, вакыйга урынында тикшерү төркеме булган. «Каберлекләрне мәсхәрәләү» маддәсе нигезендә җинаять эше ачылган. Бәчек авылында яшәүче 20 яшьлек егет шик астына алынган. Ул үзенең җинаять кылуын таныган, моны аның гаилә әгъзалары да раслаган. Тоткарланган егет психик авырулар исәбендә тора, эшкә сәләтсез дип табылган, шуңа да үз гамәленең сәбәбен аңлата алмаган.

Эльвира МОЗАФФАР,
Казан – Яшел Үзән, Бәчек

ТУКАЙНЫҢ ТУГАННАРЫ ҖИРЛӘНГӘН ЗИРАТ

Бәчек – чагыштырмача кечкенә авыл. Биредә 142 кеше исәпләнә. Халык тату, дус яши. Бәйрәмнәрне гөрләтеп уздыралар. Яз көне зиратны җыештырырга да өмәгә бергәләп чыгалар. Авылда булган бу хәлләрдән алар хушсыз калган. Берни аңлый да, аңлата да алмыйлар. Без килгән көнне зиратта берничә кеше үз туганнарының кеберләрен төзекләндерә иде. Рәмис Абдулхаков үзе Яшел Үзәндә яши. Авылдагы туган нигезенә еш кайтып йөри. Зиратта аның туганнары, дәү әнисе җирләнгән. Бу хәбәрне ишеткәч тә, авылга ашыккан.

– Үзегез күреп торасыз, зират чиста, иркен. Халык та үзара тату яши, дошманнар да юк кебек. Күбрәк кырыйда урнашкан кабер ташлары аударылган. Кемнең зиратка үче булган – билгесез. Без барыбыз да шок хәлендә, – диде ул.

Бәчек зираты тарихи яктан да истәлекле. Биредә бөек шагыйребез Габдулла Тукайның туганнары җирләнгән. Тарихи чыганаклар буенча, шагыйрьнең әнисенең сеңлесе Бибисаҗидә Әтнә районы Каенсар авылыннан китеп Бәчек авылында яшәгән. Аның кызы Өммеһания исә 1956 елга кадәр авыл мәктәбендә укыткан. Авылның аксакаллары бу бөек шәхесләр хакында горурланып сөйли. «Алар авылыбызга Тукай рухын алып килгәннәр», – дип дога кылалар. Ауган кабер ташларын Рәмис абый белән карый-карый, тарихи урынга узабыз. Зиратның бер башында XV-XVI гасырга караган борынгы таш саклана. Монда Казан ханлыгы чорының укымышлы кешеләренең берсе Шәгъбан бин Әсәд җирләнгән, диләр. Риваять буенча, ул хаҗдан кайтканда үлгән. Авыл халкы әлеге каберне карап тора, чардуган да тотып куйганнар. Шөкер, бу тарихи истәлекләргә вандалның кулы барып җитмәгән.

– Хәйдәр булмаса, зиратлар, мәчетләр болай ук яхшы хәлдә булмас иде. Барысын да ул башлап йөри. Аңа рәхмәт, – ди зиратта җыештырып йөргән икенче берәү.

Авылның имам хатибы Хәйдәр Сибгатуллин турында әйтүе. Ул өмәгә чыга алмаган. Бу вәхшилекне бик авыр кичерә.

– Кулга эш бармый, йоклап та булмый, бар тынычлыкны алды бу хәлләр, – дип каршы алды ул безне.

Хәйдәр хәзрәт сөйләвенчә, беренче тапкыр зиратта кабер ташларын 2012 елда мәсхәрәләгән булганнар. Ул вакытта бу эштә Чуашия Республикасыннан берәү шикле дип танылган. 2014 елда да берничә ташның урыныннан кучкәнен сизгән бәчеклеләр. Быел исә 30 апрельдә – 93, аннары 14 майда 113 кабер ташына зыян килгән. Дүрт таш бөтенләй куеп булмаслык хәлгә җиткерелгән, ди.

«ЮЛӘР БИТ УЛ»

Әлеге эштә кем гаепле? Бу – авыл халкы, тикшерүчеләр өчен дә иң катлаулы сорау. Дөрес, кабер ташларын аударуда шикләнелүче кеше тоткарланган. Ул – шул авылда туып-үскән 20 яшьлек психик яктан сәламәт булмаган егет. Хәзер психиатрия хастаханәсендә тикшерү уза.

– Бу эшне нәкъ ул егет кылган дип ышандырып әйтеп булмый анысы. Тик ул үзе гаебен таныган. Мин дә аңа башта ышанмадым. Ябык кына гәүдәле югыйсә. Тикшерүчеләргә бу эшне ничек эшләгәнен күрсәткәч, уйланып калдым. Ничек кенә булмасын, гаепле суд билгеләячәк. Халык гайбәт сүзләр күп сөйли. Ә мөселман кешесенә фаразлау тыелган. Ул егетне тоткарлауда кемдер миннән шикләнә. Тик хәзер Сталин заманы түгел ләбаса. Шик булмаса, кешене тоткарламыйлар. Нахак яла ягучылар бар, шуңа йөрәк әрни. Сәдакага җыелган акчага мәчетне халык белән бергә ремонтладык. Авыл көнен уздыру, Тукайга багышлап чара оештыру нияте дә бар иде. Хәзер берни эшлисе килми. Мәчеттән китәргәме әллә дип тә уйлыйм. Күңел кайтты. Бар да яхшы булсын дип йөргәндә, ашка таш белән аталары бик авыр. Алладан бары сабырлык сорыйм, җиңеллек киләчәк, иншалла. Бу хәлләр авыл халкының бердәмлеген какшатмасын иде, – ди күз яшьләре белән Хәйдәр абый.

Авыл халкының әлеге хәлләргә карата – үз фикере. Күбесе тоткарланган акылга зәгыйфь егетне кызгана.

– Ул мондый эшне эшли ала дип әйтеп булмый. Әти-әниләре – көтүчеләр аның. Бер апасы бар. Мин урамга бик чыгып йөрмим, кешедән ишеткәннәрне генә әйтәм, Имеш, шул малайның әнисе: «Улым телевизордан бокс уйнаганны кызыгып карый. Бу арада да кулына пирчәткә киеп чыгып китә», – дип сөйләгән булган. Шулай да авылдашыбыз бу эшкә бара алган дип әйтә алмыйм, – ди Фирдәвес апа.

Кибеттә җыелып торган апалар да егетне яклый.

– Сез аны белмисез бит. Ул сөйләшә дә белми, кешегә зыян китерә торган малай түгел. Юләр бит инде. Өйдән чыгып кул болгап кына тора ала. Син гаепләме дигәч, «мин» дигәндер инде. Әнисе дә зәгыйфьрәк аның. Нәрсә әйтсәләр, шуңа ышана. Хәзер менә күрсәтмәләр бирәләр, шәһәрдән кайтып кергәннәре юк. Көтүчеләрсез калдык. Зиратка барырга да куркабыз, – дип сөйләде исемен әйтергә теләмәгән берәү.

Шул ук вакытта бу егетнең, тәмәке көйрәтеп, үз йортында янгын чыгаруы турында да ишеттек.

Бәчек халкы хәзергә билгесезлектә яши.

– Тикшерүчеләр таштагы калган бармак эзләрен алдылар. Дәлил материллары да тупланды. Экспертиза нәтиҗәләре июнь аенда гына билгеле булачак. Кем гаепле икәнне Аллаһы үзе генә белә инде, – ди Түбән Урысбага җирле үзидарә башлыгы Наил Гатауллин.

Киләчәктә таш урынына бәлки элмә такта гына куяргадыр дигән тәкъдим дә булган. Зиратка камера урнаштырырга, каравылчы куярга кирәк дигән фикерләр дә бар. Авыл халкының куркып яшәве, зиратны кешеләрдән сакларга мәҗбүр булуы кызганыч. Кешенең күңелендә булмаса, каравылчы, камера куюдан гына да мәгънә булмас, мөгаен...

Сүзен-сүзгә

Рамил Гарифуллин, *психотерапевт, психолог:*

– Психоз кешенең психикасында тайпылышлар барлыкны аңлата. Агрессив вакытта, нәрсәгәдер үпкәләгәндә сәламәт кешенең дә ачуы чыга, ә психик авыруларда бу аеруча көчәйтелгән формада һәм системалы рәвештә еш кабатлана. Мондый авырулар кеше өчен кыйммәтле әйберләргә зыян салырга мөмкин. Алар моны үч алу, көнләшүдән эшли, әйтик, берәү чит ил машиналарын тырнап йөри иде. Кемдер зыян салудан канәгатьлек ала. Ташның гөрселдәп ауган тавышы авыруга рәхәтлек бирергә, аны тынычландырырга мөмкин. Шунысын да искәртергә кирәк, тәҗрибәмнән күренгәнчә, дини кешеләр арасында психик авырулар күбрәк. Алар чарасызлыктан мәчеткә йөри. Әмма алар «кулланучылар» гына. «Бир» дигәнне генә беләләр. Алар теләгәнчә килеп чыкмаса, дингә үпкәлиләр, адекват булмаган эшләргә барулары да ихтимал.

Җәлил хәзрәт Фазлыев, *Татарстанның баш казые:*

– Бер дә матур эш түгел инде бу. Таш кую диндә тыелган гамәл түгел бит. Моны чиктән чыгып китү дип бәялим. Халыкта акыллы кеше базарга һәм мазарга (бу очракта зират мәгънәсендә) кагылмас дигән әйтем дә бар. Гаепләләргә Ходай җәзасын үзе бирсен.

Фәрит Мөхәммәтшин:

«Хакимият гомерлеккә бирелми. Иң мөһиме – кеше булып калу»

Татарстанның Дәүләт Советы рәисе сәясәт, хакимият, гаилә һәм тормыш кыйммәтләре турында

gossov.tatarstan.ru

«ГАДЕЛ БУЛДЫМ ДИП УЙЛЫЙМ»

– Фәрит Хәйруллович, сез гомер буе җитәкче урыннарда эшләгән кеше. Ничек уйлыйсыз: һәрчак гадел булып булдымы? Сез демократмы, әллә авторитар җитәкчеме?

– Үземне демократ җитәкче дип саныйм, чөнки гаиләдә башкаларның фикеренә игътибарлы булу, тыңлау, ишетү һәм шуннан соң гына карар кабул итү үрнәгендә тәрбияләндем. Мин моны дөрес итеп саныйм. Әти нәрсә эшләргә икәнен үзе хәл итә иде, әни белән дә киңәшләшкәннәрдер, әмма төшке яки кичке аш вакытында – кайчан ничек туры килә – ул безне, шулай-шулай итәчәкбез, дип кисәтә иде. Бервакытта да алдан әйтмичә эшләмәде.

Гадел булдым дип уйлыйм. Һәрвакыт күпчелек өчен эшләргә кирәк дигән фикердә булдым. Карарың белән килешмәгән азчылык һәрчак булачак, әмма күпчелек кабул итсә, тормышка ашырырга тырыштым. Әлеге алымым еллар белән акланды дип уйлыйм.

– Хакимлек, хакимият сезнең өчен нәрсә ул?

– Хакимият – үз уйларыңны тормышка ашыру мөмкинлеге. Тик мин беркайчан да берничи очракта да властьны уңайлылыкка, җайлылыкка ирешү дип карамадым. Ул килә дә китә. Хакимлекнең сиңа вакытлыча гына бирелүен беркайчан да онытмаска кирәк. Хатыным, еш кына: «Онытма, син парламент рәисе булып тумаган. Безнең өчен син беренче чиратта – ир, әти, бабай, гаилә башлыгы. Ничек кенә булса да, сиңа властька ия булганчы булган тормышыңа кайтырга туры киләчәк», – ди. Хакимият гомерлеккә бирелми. Иң мөһиме – кеше булып калу. Эш дәверендә үзеңне шулай куярга кирәк: еллар узу белән, үз исемеңә авыр сүзләр, гаепләүләр ишетерлек булмасын. Мин шундый уй белән эшләдем һәм яшәдем.

– Ә ялгышкан очракларда... Менә болай эшләргә кирәкмәгән дигән очрак булдымы? Бәлки сез кабул итәргә теләмәгән законнар булгандыр?

– Парламент рәисе буларак, үзең килешмәсәң дә, күпчелек карары белән кабул ителгән закон проектын имзаларга мәҗбүрсең. Синең күңелеңә ул хуш килмәскә дә мөмкин, әмма депутатлар тавыш биреп кабул иткән икән – башка юл юк, кул куясың – регламенты шундый. Яшермим, менә бу законга кул куймыйча, Татарстан Президентына, Дәүләт Советына эшләп бетерергә кайтарыгыз әле, дип мөрәҗәгать иткән вакытларым булды. Ул кайтарса, кабат шул закон буенча фикерләшәсең, каршыларны аны төзәтергә кирәклегенә инандырырга мөмкинлек арта. Тик бер нәрсә төгәл: үзем кул куйган бер генә документ турында да эшләми торган яки халыкка каршы документка кул куйдым дип әйтә алмыйм.

СПИКЕР СЕРЕ

– Фәрит Хәйруллович, Дәүләт Советының һәр сессиясе – үзе бер сынаудыр. Теләсә нинди сценарийга әзер булу өчен нинди сыйфатларга ия булу кирәк? Уңышлы спикер сере бармы?

– Сабыр булырга һәм чама хисен югалтмаска кирәк. Үз фикереңне яклау өчен һәр мәсьәләне төбенә төшеп өйрәнү мөһим. Спикер сере турында еш сорыйлар. Әгәрниндидер аерым серем, кагыйдәм бар дип санасаң да, ул бик гади: мин, 10-15 ел элеккеге кебек үк, һәр сессиягә ныклап әзерләнәм. Бөтен җитди сорауларны – ә Дәүләт Советында җитди булмаганнары юк – без комитетлар рәисләре, хокук идарәсе белән «сүтеп җыябыз». Әзерләнгән проектларны федераль

законнар белән чагыштырабыз, үзебезнең законнарны күтәреп карыйбыз: каршы килгән урыннары юкмы, килешмәгән очраклар калмасын... Утырыш алдыннан кич белән депутатлар тәкъдим иткән бөтен төзәтмәләрне тагын бер тапкыр карап чыгам. Кыскасы, барысы да бик гади. Дәүләт Советының һәр утырышы – алып баручы гына түгел, ә һәр катнашучы өчен имтихан, имтиханга әзерләнми бармыйлар бит.

Сыйфатлар дисез. Эмоцияләреңне күрсәтмәү, үз-үзеңне кулда тоту – теләсә кайсы сәясәтче өчен алыштыргысыз сыйфатлар. Сүз уңаеннан, андый сабырлык эштә генә түгел, өйдә, гаиләдә дә кирәк. Мин ул чыныгуны беренче чакырылыш Югары Совет рәисе вазифасында алдым. Үз исемемә яки республика адресына ничәмә-ничә тапкыр тәнкыйть сүзләре ишетеп, салкын канлылыкны күрсәтергә туры килде! Сәясәттә бөтен уйлаганыңны әйтүгә караганда, дәшми калу әйбәтрәк.

– Сез, вазифагыз буенча, халык белән иң еш аралаша торган җитәкчеләрнең берсе. Күңелгә иң нык тәэсир иткән аралашулар булдымы?

– Дөрес әйтәсез, тормыш шулай килеп чыкты: мин һәрвакыт халык арасында булдым. Бервакытта да бер аудиториядән дә курыкмадым. Нинди генә каршы фикерле, тәнкыйтьчел аудитория булса да, курыкмый чыктым. Хакимияттә эшләгәндә дә, Югары һәм Дәүләт Советында да бик кайнар сораулар буенча, кызган төркемнәрдә чыгыш ясарга туры килде. Беренче вакытларда үземне татар телле мохиттә кимсенүле хис итә идем, чөнки татарчам аксый иде. Аннан, ә мин кемнән ким дип, өйрәндем, үземә ышанычым да артты.

Минем өчен ниндидер зур рәсми залларда яңгыраган сүзләр дә, урамда халык төркеменнән чыккан сүз дә һәрвакыт мөһим булды. Ничек кенә тәнкыйтьләсәләр дә, игътибар белән тыңладым. Сабыр гына тыңлау һәм сине тиргәгән кешегә тискәре җавап бирмәү кирәк. Әгәр син сабырсыз һәм халыкны яратмыйсың икән, ул бик тиз сиңа каршы чыгачак. Бу минем өчен тормыш кагыйдәсе.

– Сезнең өчен иң яхшы депутат ул нинди?

– Иң яхшы депутат – комитет, сессия утырышларын бер дә калдырмый, актив катнаша, үз фикерен белдерә, тәкъдимнәр кертә торган депутат. Иң яхшы депутат – әйткән белән генә ризалашып утырмыйча, сиңа каршы төшеп һәм шуның белән беррәттән үз фикерен дәлилләп, яңа тәкъдим дә кертүче депутат. Теләсә нинди закон берәр максатны күзаллый. Максат – бер, аңа ирешү юллары гына төрле. Коллегаларың арасында, мин бу юлда шикләнәм, менә болай карап карыйк әле, дип әйтүче кеше бар икән, ул – уйлаучы, кайгыртучан депутат. Андыйларны бик хөрмәт итәм.

– Дәүләт Советы рәисе вазифасында үзегезнең иң югары казанышыгыз дип нинди казанышны саныйсыз?

– 25 ел эчендә, Татарстан парламентчылыгы үскән чорда, без хаостан, ягъни төптән уйламыйча законнар кабул итүдән киттек. Килеп терәлде – кабул итәргә кирәк дигән әйбер юк. Парламентны системалы закон чыгару юлына китердек. Хокук кырын кирәксез, эшләмәүче, бер-берсенә каршы төшкән законнардан чистарттык. Хәзер, еллык эш планын төзегәндә, системалы закон чыгару юнәлешендә эшлибез. Һәм, әлбәттә, безнең тормышыбыз башкарма комитетларның вакытлы нормативлары белән түгел, Татарстан законнары белән көйләнгән булсын дип тырышабыз.

ГАИЛӘ НЫКЛЫГЫ

– Фәрит Хәйруллович, гаилә үзе бер дәүләт. Анда законнар яңарып торырга тиешме?

– Гаилә – җәмгыятьнең нигезе ул. Гаилә кыйммәтләрен еш үзгәртеп торсаң, миңа калса, фундамент какшаячак. Ул – законнар беркайчан да үзгәрмәскә тиешле үзенчәлекле дәүләт. Традицияләр белән яшәргә тиешле дәүләт. Әйтик, синең үзеңә инде – 70, улыңа 50 яшь тулган, ә син әле һаман үзеңне аның өчен җаваплы дип саныйсың. «Әти нәрсә әйтер?» дигән уй, юк-юк та, әле дә башыма килеп ала. Үземнең улымда да шулай дип уйлыйм. Бу һәр нормаль гаиләдә тәрбияләнгән кешедә булырга тиешле әйбер дип саныйм. Бер-береңә өчен һәм бер-береңә каршында җаваплылык. Кайберәүләр моны артык кайгырту дип атар, дөрес түгел диярләр. Минемчә, җаваплылык хисе булу һәм аның киләсе буынга да күчүе – зур әйбер. Һәр шимбә балаларың һәм оныкларың белән күрешү традициясе булу – тагын бер искиткеч әйбер. Син ул очрашуларда гаилә кыйммәтләрен киләсе буынга тапшырып калдырасың. Оныкларың бу мөнәсәбәтләрне күрә, гаиләдә ата-анага игътибар нинди булырга тиешлегенә өйрәнә. Оясында ни күрсә, очканында шул булыр, дип юкка гына әйтмәгәннәр бит. Без шуңа ияләштек, шунсыз яши алмыйбыз. Әгәр иртәнге сигезенче яртыда һәм кич эштән соң кызыбыз әнисенә шалтыратмаса, без борчыла башлыйбыз. Улым көн дәверендә миңа бер шалтыратып алмаса – шул ук хәл. «Балалар шалтыраттымы?» – Луиза белән бер-беребезгә көн дә бирелә торган гадәти сорау. Без оныкларның өй эшләрен ничек әзерләвен, контроль эшләрне ничек эшләве турында белеп-белешеп торабыз.

– 70 яшьлек юбилеегызны ничек каршы алачаксыз?

– Төрле уйлар булды. Гомер иткән хатының белән икәү генә берәр чит илгә китеп тыныч кына уздырыйкмы әллә дип тә уйлаган идек. Ләкин эштә янәшә эшли торган кешеләр икенче фикер тудырдылар. Син үзең генә түгел, җәмгыять кешесе, җыелышып, туган көнеңне бергә үткәрик дип, кире күндерделәр. Күп кеше җыймыйм, бергә эшләгән кешеләрне, якыннарымны, туганнарымны гына чакырып, ун ел элек җыелган рестоpанда шул ук состав белән утырырга булдык. Хәтта алып баручы да шул ук булачак.

– Тормыштан бөтен теләгән әйберегезне алдыгызмы, Фәрит Хәйруллович?

– Тулы бәхет беркайчан да булмыйдыр ул. Тормыш, эш көн саен яңа бурычлар куя, аларны хәл итәргә кирәк. Эшем, гаиләм, балаларым бар. Хөрмәткә дә иямен кебек. Миңа калса, бу аз түгел...

Әңгәмәдәш – Гөлнара САБИРОВА.

Ул бит татар малае!

Бер ел элек Арслан Сибгатуллин – ул вакытта өч яшьлек малай – Габдулла Тукайның «Туган тел»ен сәнгатьле укуы белән шаккатырган иде. Быел 9 май тирәләрендә инде дүрт яшен тутырган «егет», «Священная война» җырын җырлап, интернетны «шартлатты». Федераль каналлар да аны күреп алды.

«О, БӨЕК ТУКАЙ!»

Әнисе – Камал театры артисты, ГИТИС студенты Гүзәл Сибгатуллина Арсланны ничек тәрбияләве турында сөйли. Ул Пушкин әкиятләрен тыңларга яраткан, шуларны укымыйча йоклап китмәгән. Бигрәк тә «У лукоморья дуб зеленый» ошаган икән. Аны кат-кат укыткан. Аннары әнисенә кушылып, үзе дә яттан сөйли башлаган. Соңрак Арслан джаз белән кызыксына башлаган. Кумиры... ышансагыз ышаныгыз, ышанмасагыз – юк, Майкл Джексон булган. Ике яшьлек чагында ук ул әнисен, Майклдагы кебек эшләпә, пирчәткәләр эзләтеп, кибеттән кибеткә йөртеп аптыраткан. Телевизордан да гел аны гына караган, аны гына тыңлаган. Хәтта мультфильмнарга да бик исе китмәгән ул чакта.

Үзе Алексеевск районының Ялкын авылында укытучы гаиләсендә туган телгә мәхәббәттә үскән Гүзәл, билгеле инде, улын Тукайга якынайтырга теләп, аның әкиятләрен, шигырьләрен дә укый башлаган. Шул чакта Арсланның осталыгын күреп алып (бу вакытта инде ул бакчага йөри башлаган булган), Совет районында даими уза торган «Талантлы бәләкәч» бәйгесендә катнашыр өчен берәр шигырь өйрәтегез әле дигәннәр тәрбиячеләр. «Туган тел»не шулай өйрәнгәннәр. Дөрес, башта әнисенә улы аңларлык телдә туган телнең әһәмияте турында шактый аңгәмә алып барырга туры килгән. Аның каравы, нәтиҗәсе сөендерерлек булган. Малай, әнисен шаккатырып: «О, Бөек Тукай!» – дип кычкырып җибәргән. Арслан, үзенең сакау сабый теле белән, татарның гимнына әйләнгән әлеге шигырьне туган телен белмәгән һәркемне оялтып-кызартырлык, манкортны да уятырлык итеп җиренә җиткереп сөйли шул. Зәңгәр күләпүшле, телен фәрештә үпкән бу малайга һәркем сокланды ул чакта. Шигырь бәйрәме көнне һәйкәл янында да чыгыш ясарга килгәч тә, Арслан шулай сәламләгән бөек шагыйрьне.

ГАМЛЕТ

Аннары Арслан Гамлет белән танышкан. Камал театрында «Тантана» кичәсендә Ирек Баһмановның әлеге рольне уйнаган костюмын киеп, Гамлет булып сәхнәгә чыккан малайны тамашачы бик озак алкышлап, җибәрми торган. Малайга өч тапкыр чыгып баш ияргә туры килгән.

– Сәхнә аның үз өе төсле. Ул анда чыгарга курыкмый да, оялып та тормый. Берсендә тиздән сәхнәгә чыгарга тиеш улым көйсезләнә башлады, аннары елап ук җибәрде. Бетте баш дип уйлыйм, ул бит әле сабый, үзе теләгәнне генә эшли. Ә аның тизрәк сәхнәгә чыгасы килә, көтеп арыган икән! – ди Гүзәл ханым, елмаеп.

Гамлет интернетны йөреп чыккач, Арсланны әнисе белән Мәскәүгә Беренче каналда баручы «Лучше всех» проектына чакырдылар. Анда тапшыруны яздырганда, балаларны каушатмас өчен, әниләрне кертмиләр икән. Арыслан бик тиз ияләшә студиягә. Гамлет монологы белән башлап, «Эх, сез матур кызлар!»га кадәр җырлап күрсәтеп, барысын да шаккатыра. «Священная война» җырын да җырлый. Казаннан килгән терекөмеш кебек тере, тиктормас татар малаен бик яраталар. Ләкин тапшыруның үз кануннары бар икән. Анда сугыш темасы күтәрелмәскә һәм номерлар кабатланмаска тиеш. Гамлет белән килгән балалар бик күп булганга күрә, Арсланны кабат очрашулар теләп, яңа репертуар булдырырга кайтарып җибәрәләр.

«МИН СУГЫШТАН КУРКАМ»

Арслан башкаруында «Священная война» җыры Җир шарын әйләнеп чыкты диярргә була. Кайлардан гына шалтыратмаганнар, язмаганнар. Хәтта Дагыстаннан бер шагыйрь аңа багышлап шигырь дә язып җибәргән. Англиядән, Америкадан да сокланган хәбәрләр бүгенгә кадәр килә ди. «Священная война»ны кыш көнендә үк яздыра башлаганнар.

– Әни миңа бу җырның зур сугыш турында булуын сөйләде. Анда бик күп кешеләр үлгән. «Син бу җырны бөтен сугыш булмаслык итеп, бар илне күтәрерлек итеп җырларга тиеш!» – диде. Мин сугыштан куркуымны, аны яратмавымны һәм барлык балаларның да сугышны яратмавын шушы җырымда җырладым. Тырышып җырладым. Бар көчемне биреп, – ди Арслан.

Арслан – ГИТИСта укучы әнисенең «практик эше». Ул, яраткан әни булып та, оста режиссер булып та зур тырышлык куеп, улындагы сәләтне соклангыч талантка әйләндергән. Алда әле Гүзәл ханымның диплом эшен яклыйсы бар. Димәк, без Арсланның осталыгына кабат сокланачакбыз, күз генә тидермик, берүк.

Йолдыз ШӘРАПОВА.

«ШӘҺРИ КАЗАН»НАН – АЛМА БАКЧАСЫ

Эх, алмагачлары!

Бу язылу кампаниясендә «Шәһри Казан» үзенең укучылары өчен гадәти булмаган бүләк әзерләде – акциянең таләпләрен төгәл үтәп, редакциягә анкета юллаучылар арасында алмагачлар уйнатабыз. Инде ул агачларны ничек итеп утыртырга, дөрес тәрбияләргә кирәклеге турында сөйләшергә дә чират җиткәндер. Югары Ослан районының Янбулат авылындагы «Заря» хуҗалыгында агроном булып эшләүче Гөлчәчәк Әхмәтҗанова үз киңәшләрен бирде.

Исегезгә төшерәбез, алмагач үсентесенә ия булу өчен, 2017 елның II ярты еллыгына «Шәһри Казан» газетасына язылырга һәм квитанция белән анкетаны тутырып, редакциягә юлларга кирәк. Җиңүче очраклы саннар генераторы ярдәмендә билгеләнә.

Бу атна җиңүчесе – Казаннан Рузилә Абдуллина. Котлыйбыз!

Видеосы www.shahrikazan.com сайтында. Чираттагы җиңүчене 31 май көнне билгеләячәкбез.

Эльвира МОЗАФФАР

ГӨЛЧӘЧӘК АЛМАГАЧЛАРЫ

«Заря» агрофирмасы – Татарстанда алма җитештерү белән шөгыльләнгән сирәк хуҗалыкларның берсе. Биредә уҗым культуралары да үстерәләр, терлекчелек белән дә шөгыльләнәләр анысы. Тик менә бакчачылык аерым урын алып тора. Без килгәндә, агроном Гөлчәчәк Әхмәтҗанова теплицада көндәлек эшләре белән мәшгуль иде.

Биш теплицада ниләр генә үстермиләр: чәчәктән алып декоратив куакларга кадәр бар. Аеруча зелпе агачын еш сорыйлар икән. Витаминга бай җимешләрен халык сәламәтлекне ныгыту өчен файдалана. Карлыган, җиләк, крыжовник та бар теплицада. Иң түрдә – алмагачлар.

– Алмагачны үстерү турында тулы бер энциклопедия белемен сөйли алам мин сезгә, – дип көлә Гөлчәчәк.

Ул һәр килгән сатып алучыга киңәшләрен бирә, агач сайларга булыша. Гөлчәчәкнең кулы җиңел, диләр, үсенте алырга килгән кешеләр дә ул сайлап биргәнне көтәләр икән. Хәтта «Гөлчәчәк алмагачлары» дип исем дә биргәннәр.

– Безнең үсентеләр сыйфатлы санала. Беркайчан да алдамыйбыз. Шуңа ерак районнардан кадәр бирегә киләләр, – ди агроном.

«Гөлчәчәк алмагачлары» барлык Татарстан буенча таралган. Арча, Апас, Кайбыч, Кама Тамагы, Югары Ослан районыннан, Казаннан килүчеләр күп.

Бакчачының эше кыш көне дә бетми. Өч кеше кыш буена 3 мең төп алмагач әзерләгән. Бу үсентеләрнең кечкенә генә орлыктан үсеп чыкканына ышанып та булмый. «Заря» хуҗалыгының питомнигында инде алма биргән алмагачлар бар. Бакчачылар теле белән әйтсәк – «маточник»лар. Алардан кисеп алынган ботакларны орлыктан үсеп чыккан үсентеләргә ялгыйлар. Бу үсентеләр теплицада бер-ике ел дәвамында үсә, ныгый. Мондый алмагач үсентеләре бакчага күчереп утырту өчен яхшы санала, бәяләре 400-500 сум тора.

Теплицада – 20 сорттан артык алмагач. Халык арасында иң популярлары: баллы, тәмле «Конфетное», үтә күренмәле булып өлгерә торган саргылт «Медуница». Көзге сортлардан шәм белән капланган кебек ялтырап торган «Жигулевский» төре яхшы, ул кышка да әйбәт саклана. Укучыларыбызга – акция җиңүчеләренә – «заря»лылар иң тәмле, сусыл алма бирә торган «Кутузовец» һәм «Грушовка» сортларын сайлап бирделәр.

АЛМАГАЧЛАР ЧӘЧӘК АТА МАЙНЫҢ УНБИШЛӘРЕНДӘ

Алмагачтан тыш биредә Әстерхан карбызы, кавын, помидор кебек яшелчә, җиләк-җимеш үсентеләрен дә сатып алырга була. Быел Гөлчәчәк 10 мең төп чәчәк утырткан. Тузан бөртеге кебек орлыкларны һәр чиләккә берәмләп утырта ул. Махсус машинасы юк. Барысын да кул белән эшли. Иренми дә, зарланмый да.

– Ялкау кеше бакчачы була алмый. Эшне иртәнге сәгать биштә дә башларга, кичке сигезләргә кадәр теплицада булырга да туры килә. Ничек кенә булмасын, бу эш миңа рәхәтлек бирә. Үзем Гөлчәчәк булгангамы икән, чәчәкләр бик яратам, – ди үзе.

Теплицаларда күп эшне үзенә эшләргә туры килә. Авылда эшкә килүчеләр сирәк. Эшче көчләрне күрше Чуашия ягыннан вахта белән алып килергә туры килә. Эшчеләр тулай торакта яшиләр. Аларга барлык шартлар да тудырылган. Сәгатенә 70 сум хезмәт хакы түлиләр. Тик үсентеләрне сирәкләү, күчереп утырту кебек эшләрне бөтен кешегә ышанып тапшырмый Гөлчәчәк.

Баксаң, алмагач бакчасына фотога төшәр өчен килүчеләр дә бар. Алмагачлар чәчәк аткан вакыт – туй фотосессияләре ясар өчен матур. 465 гектарга сузылган мәйданда ап-ак чәчәкләр арасында үзеңне әкияттә кебек хис итәсең.

«Алмагачлар чәчәк ата Майның унбишләрендә»,

– дип җырланса да, быел май салкын килү сәбәпле, чәчәк ату чоры да соңлаган. Аның каравы, тәҗрибәле бакчачылар яфрак буенча карап билгеләгәннәр – быел алма ишелеп уңарга тиеш. «Заря» хуҗалыгында 20 мең тоннага исәпләнелгән җиләк-җимеш саклана торган урын ясаганнар. Суыткычлар гына аласы калган. Татарстан халкын елына меңләгән тонна алма белән тәэмин иткән хуҗалык өчен бу бик мөһим. Быел «Заря» алмаларын кышын да, язын да ашарбыз әле, иншалла.

Агроном **Гөлчәчәк Әхмәтҗанова**дан алмагач утырту буенча киңәшләр:

– Алмагачны язын, көзен утыртсаң да ярый. Утыртыр өчен бер еллык алмагачларны сайласагыз отышлырак. Алмагачның зурлыгына карап, 60 сантиметрга 60 сантиметр зурлыкта чокыр казыйсың, анда черемә салып калдырасың. Үсентене ялганган ягын өстә калдырып утыртасың. Нәзек кәүсәле алмагач җилдә сыгылып бөгелмәсен өчен, аны берәр таякка беркетеп бәйләргә киңәш ителә. Алмагач ныгып киткәнче суны даими сибеп торырга кирәк. Язын төрле бөҗәкләрдән саклау өчен, агач төбен акшар белән агартсаң яхшы. Акшар шулай ук кәүсә кояшта артык кызып ярылмасын өчен дә кирәк. Гадәттә, үсентеләргә телә төшеп азаплый. Мондый очракта яз көне бөҗәкләрдән саклый торган махсус препарат сиптерергә кирәк. Кайбер кешеләр, теләне кайнар су үтерә икән дип, март аенда су сибә. Әмма бу зур хата. Телә суда үлми, яз көне барыбер чыга. Ә менә салкында сибелгән су үсентегә зыян китерергә мөмкин. Күп кеше, алмагачым биек үсә, дип зарлана. Монысы һәркемнең үзеннән тора. Алмагачның иң биек очын кисәргә кирәк. Бу очракта ботаклар ян-якка чыга башлый. Шул рәвешле, алмагач матурланып китә. Алмагачның гомере – 25-30 ел. Аннан соң җимешләре вагая, тәме үзгәрә. Ботаклары гөмбә белән каплана. Карт алмагачны алыштырырга кирәк.

АНКЕТА

1. Исем-фамилия, адрес, телефон______________________________

____

2. Яшегез______________________________

3. Шөгылегез______________________________

4. «Шәһри Казан» газетасын кайчаннан бирле алдырасыз?______________________________

____

5. Газета белән беренче тапкыр ничек һәм кайда таныштыгыз?______________________________

____

6. Газетага ничек язылдыгыз:

почта бүлекчәсендә _____

хат ташучы өйгә килә _____

интернет аша _____

____

7. Газетаны кайсы битеннән укый башлыйсыз?

____

8. Сезне нинди эчтәлектәге язмалар җәлеп итә?

____

____

9. Газетада тагын нинди темаларның күтәрелүен телисез?______________________________

____

____

10. Газетаның миңа иң ошаган:______________________________

____

____

ошамаган яклары:______________________________

____

11. Тагын нинди газета-журналлар алдырасыз?

____

____

Гөлчәчәк Фәтхуловадан тәмле өчпочмаклар

АШ БУЛСЫН

Камыр өчен: 200 гр кибет каймагы, 100 гр бүлмә температурасындагы су, 100 гр эретелгән ак май, бер чеметем тоз, бер чеметем шикәр комы, ярты чәй кашыгы көпшәкләндергеч (разрыхлитель), он.
***Эчлек өчен:** тавык ите, бәрәңге, суган, тоз, борыч.*

Гадәти өчпочмак камырыннан катырак итеп камыр басабыз. Ни өчен дигәндә, камырны бераз ял иттергәч, ул артык йомшарып китә. Йомшак камыр өчпочмакны ясаганда тишелергә йә булмаса ясагач, җөйләре яхшылапябышмаска, ачылырга мөмкин. Камырны бераз ял иттерәбез. Ул арада эчлек әзерлибез. Камырыбызны вак кисәкләргә бүлеп, түгәрәкләр җәеп, өчпочмакны ясап, кызган газ мичәнә куябыз. Пешеп чыккач, өстен майлап табынга бирәбез.

ХАТЫН-КЫЗЛАРГА

Кыска чәч килешәме?



Моны белү өчен карандаш алып, аны горизонталь рәвештә ияк астына куябыз. Колак очыннан вертикаль рәвештә линейка куябыз. Карандаш белән линейка 90 градус почмак белән кисешергә тиеш. Әлеге урын 5,715 см дан ким булса, чәчегезне курыкмыйча кистерә аласыз.

МӘЛЕНӘ – ӘМӘЛЕ

Кер юу машинасы озак хезмәт итсен дисәгез

- Керне машинага күп тутырмагыз. Авыр керләр аның механизмын боза. Артык зур әйберләрне химчисткага бирегез.
- Керләрне алганнан соң, машинаның ишеген ачып калдырыгыз. Эче дымланып торып, күгәрек барлыкка килергә мөмкин.
- Берничә тапкыр юдырганнан соң, юшкынга каршы махсус порошок салыгыз.
- Кер юу машинасының режимнары күптөрле. Һаман бертөрле режим кулланырга ярамый.
- Порошокны күп кулланмагыз, югыйсә машинаның моторы һәм торбаларына зыян киләчәк.
- Кер юу машинасыннан могҗиза көтмәгез. Ул кайбер тапларны бетермәскә дә мөмкин. Димәк, аларны машинага салганчы ук бер кат чистартырга кирәк.
- Машинаның фильтрын даими рәвештә чистартып торыгыз.

БАКЧАЧЫГА

Капчыктагы кыярлар

Венера МӘҖИТОВАдан сыналган ысул

Барыгыз да беләсездер, кыяр тәнлә үсә, икенчедән, ул җылы ярата. Менә шуларны искә алып, соңгы елларда мин кыярны капчыкта үстерә башладым. Төнгелеккә кыярлы капчыкларның өстен прищипка белән беркетеп куям да иртән ачам. Җылы яратучы үсемлек буларак, кыяр үсентеләре капчык эчендә үзләрен бик яхшы хис итәләр. Салкыннар беткәнче шулай эшлим: бер ачам, бер ябам. Төннәр җылынгач та, кыярларны капчыкта калдырам, җиргә күчереп утыртмыйм. Көзгә кадәр алар капчыкта үсеп утыралар. Калган кыярларны, салкыннар бетеп, төннәр ныклап җылынгач кына теплицага утыртам. Билгеле инде, капчыктагы кыярлар теплицадагы җиргә утыртылганнарына караганда тизрәк өлгерәләр. Ошаса, сез дә шулай итеп карагыз. Кыярны шулай үстерүнең бер авырлыгы да юк. Аның каравы, иртә яздан ук кыяр белән сыйлана башларга була. Узган ел 9 майда тәүге кыярны өзгән булсам, быел, яз соң килү, төннәр салкын тору сәбәпле, капчыктагы кыярлар әле дүрт яфракта гына утыралар. Озакламый төннәр җылыныр, кыярлар да, кояшка үрелә-үрелә рәхәтләнеп үсә башларлар дип ышанып калам. Шунысын да әйтим, төнгелеккә мин теплицага җылыту приборы куям. Кыярлы капчыкларны да шуның тирәсенәрәк урнаштырам.

БЕЛЕП ТОР!

Тәрәзәләре көлеп тора

Кояшлы көннәрдә тузанлы тәрәзәләр аеруча күзгә бәрелеп тора. Әллә кайдан ялтырап көлеп торсын дисәгез, аларны түбәндәге катнашма белән юыгыз.

Өч чәй кашыгы суга җиде чәй кашыгы глицерин һәм берничә тамчы нашатырь спирты кушыгыз. Кәгазь салфеткаларны шул катнашмага манып, тәрәзәләрне чистартыгыз.

МАТУРЛЫК САЛОНЫ

Куллар кытыршы булганда әлеге рецепт ярдәмгә килә

Даруханәдә сатыла торган глицеринга аш серкәсе кушабыз. Глицерин шешәсе авызына кадәр тулмаган була, серкәне аңа кушу авыр түгел. Катнашманы яхшылап болгатыгыз да иртән-кич кулларыгызга сөртегез.

ШӘП ИДЕЯ

Бакчаны гап-гади әйберләр белән дә бизәп була

ХУҖАБИКӘГӘ

Йөрәк формасындагы торт ясарга теләүчеләргә

Ябыгасым килә...

Карабодай боткасы – 100 граммда 120 ккал
солы боткасы – 100 граммда 160 ккал
арпа боткасы – 100 граммда 88 ккал
борчак боткасы – 100 граммда 80 ккал
кукуруз боткасы – 100 граммда 86 ккал
дөге боткасы – 100 граммда 144 ккал
тары боткасы – 100 граммда 89 ккал
манный боткасы – 100 граммда 100 ккал

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА әзерләде.

АВЫЛ ТУРИЗМЫ:

firdusmingazov.ru

vk.com

АКТУАЛЬ ТЕМА

Соңгы елларда авыл туризмы турында күп сөйләшәбез. Аны билгеле бер системага салырга, авыл территорияләренең комплекслы туристик продуктын таныту өчен интерактив карта төзергә, аерым сайт булдырырга, бу эш белән шөгыльләнүчеләргә ярдәм күрсәтергә кирәк дибез. Тик нишләптер шул сүздән ары уза алмыйбыз.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА

Авыл туризмының бизнес өчен файдасы юкмы, әллә ул безнең халык өчен кызыклы проект түгелме? Нишләп бу өлкәдә алга китеш юк? Әлеге сорау белән мин Авыл туризмы төбәкара ассоциациясе рәисе **Руфия Мөхәммәдиева**га мөрәҗәгать иттем.

– Авыл туризмы белән фәкать безнең оешма гына шөгыльләнә. Без дәүләттән акча алмыйбыз, коммерцияле булмаган оешма саналабыз. Бу зур эштә дәүләт структураларының да катнашуы зарур. Уртак көч белән аны билгеле бер калыпка салырга, закон нормаларына үзгәрешләр кертергә кирәк. Авыл туризмы белән Авыл хуҗалыгы министрлыгы да, Туризм комитеты да тиешенчә шөгыльләнми. Ә моның өчен махсус законнар кирәк. Агротуризм буенча закон проекты Дәүләт Думасында 2007 елдан бирле ята. Ул һаман да каралмаган. Белоруссияне мисал итеп күрсәтәсем килә. Анда агротуризм белән унбиш ел шөгыльләнәләр. 2500 комплекс шушы төр эшчәнлеккә җәлеп ителгән. Аларның 600-700е актив эшләп килә. Авыл туризмы субъекты елга ун доллар база салымы түли. Башка бернинди дә салым түләми. Америкада авыл хуҗалыгы эшчәнлеге белән шөгыльләнүче фермер шушы эшкә җәлеп ителсә, шулай ук бернинди дә салым түләми. Бездә исә мескен фермерлардан иң беренче булып салым түләтү максаты тора.

Россия буенча авыл туризмы белән актив шөгыльләнүче 11 төбәкне аерып күрсәтергә була. Алар арасында әлегә Татарстан юк. Аның каравы, без аңа омтылабыз. 2015 елдан бирле акрынлап кына шуңа барабыз. Бу башлангыч кына әле.

– Агротуризм белән шөгыльләнүчеләргә яки бу эшкә алынырга теләүчеләргә берәр ярдәм күрсәтеләме?

– Махсус шушы категория өчен дәүләт ярдәме юк. Республика буенча да, федераль дәрәҗәдә дә юк. Грант алып булмыймы дип көн дә диярлек шалтыраталар. Димәк, бу эш белән кызыксынучылар бар. Ә эшне ярдәмнән башка башлап җибәреп булмый.

– Авыл туризмын үстерүдә төп проблема шул акча булмау гынамы?

– Башка проблемаларыбыз да күп. Авыл туризмы белән шөгыльләнергә теләүчеләрне махсус курсларда укыту, аларны стажировкага җибәрү мөмкинлеген эзлибез. Гомумән, киләсе елга Икътисад министрлыгының бер программасы буенча, авыл туризмы үзәген булдыру идеясе бар. Ул үзәк алда әйтеп үткән мәсьәләләр белән дә шөгыльләнер дип уйлыйбыз. Хәл итәсе мәсьәләләр арасында авыл туризмы субъектлары эшчәнлеген легальләштерүне гадиләштерү, аларны зур салымнардан, кирәкле-кирәкмәгән тикшерүләрдән азат итү кебек пунктлар да бар. Бу эштә җирле хакимият органнары да катнашсын иде. Бүгенге көндә авыл туризмын үстерүчеләр үз акчаларына, үз мөмкинлекләренә карап, үз җайлары белән генә яшәп ята. Алар турында белүче дә юк, туристлык фирмалары белән дә эшләмиләр. Туристлык агентлыклары да әзер турпродукт белән генә эшли. Аларның үз таләпләре бар. Ә тегеләре ул таләпләргә туры килеп бетми. Мәскәүдән килгән бер төркем авыл туризмы белән кызыксынды. Аларны Казаннан ерак түгел бер комплекска җибәрергә уйладык. Каршы алырга тиешле як, үзләре белән ашарга алып килсеннәр, дип белдерде. Кемдә ашау юк, кемдә биотуалет, душ юк, кемдә кунып калырга кунак йорты юк, кайбер җирдә интернеты да начар тота. Безнең халык бит «барысы да кертелгән» сервисына күнеккән. Туристның ашарга пешереп тә утырасы килми. Агротуризм белән шөгыльләнүчеләрне дә аңлыйм. Боларны булдырырга әлеге дә баягы грантлар, акчалата ярдәм кирәк. Әллә нигә бер килә торган туристлар өчен махсус аш-су остасы тотарга акчасы юк. Эш аңарда гына да түгел. Махсус бизнес-проект булмауда, бу өлкәдә белем юклыкта, тәҗрибә җитмәүдә дә. Тагын бер категория кешеләр бар: әлеге эшкә алар акчага гына кызыгып тотына. Чынлыкта, ул эш үзен өченче елга гына аклый башлый. Бу әле актив эшләгән очракта гына. Агротуризмга инвесторларның да акча саласы килми, чөнки аның нәтиҗәсен төгәл генә күзаллап булмый.

ЭТНИК ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ АВЫЛ ТУРИЗМЫ

Казан, Болгар, Зөя, Алабуга, Чистай шәһәрләренә туристлар хәзер күпләп килә. Аларны таныту өчен күп көч куйдык һәм алар моны aклады. Бик теләгәндә, Татарстанны этник туризм белән дә танытырга була бит. Без республиканы күпмилләтле төбәк дияргә яратабыз. Нишләп менә шуны туризм өлкәсендә кулланмаска? Миңа калса, авыл туризмы бездә этник үзенчәлекләрне исәпкә алып та үсәргә тиеш.

– Белгород өлкәсенә баргач, авыл туризмы белән күп еллар шөгыльләнүче бер кеше белән сөйләшергә туры килде. Сезгә рәхәт, мәчетләрегез дә, чиркәүләрегез дә бар, дип әйтеп куйды ул. Туристларны шуның белән дә җәлеп итеп була бит. Этник туризмның башлангычы юк түгел, бар бездә. Алабуга районының Иске Куклюк авылында зур акчаларсыз гына да кызыклы проектлар эшли алганнар. Анда марилар яши. Мәктәп директоры Иван Мельников һәм аның улы – Аграр яшьләр берлегенең район бүлеге рәисе Николай – мари культурасы музеен ачкан. Анда килгән туристлар атларда йөри, кышын чаналарда шуа. Кара мунчага керә, кәҗә савып карыйлар, утын яралар, талдан кәрҗиннәр үрәләр, халык уеннарын уйныйлар, иҗади ансамбльләрнең чыгышларын карыйлар. Башлангычын Каспий диңгезеннән алган чишмәләре дә бар. Ул дәвалау үзлегенә ия дип ышана авыл халкы. Туристлар авылдан үзләре белән каймак, сөт, күкәй, эремчек тә алып китә. Алар берничә көнгә кечкенә генә йортта да куна ала. Күпмилләтле районнар бездә бик күп. Йөрт туристларны бер авылдан икенчесенә. Бер көндә берничә милләт белән танышa алалар бит. Питрәчтә, Әйтик, Керәшен Сәрдәсе, Шәле, Аркатау кебек өч авылны берләштергән маршрут булдыру идеясе бар. Миңа калса, ул бик кызыклы проект, Питрәч Казанга якын булгач, анда куна калу да мәҗбүри түгел. Әмма бу проект әле сөйләшү стадиясендә генә. Әлеге эш белән район администрациясенең дә кызыксынуы кирәк шул, – ди әңгәмәдәшем.

БАР ДА, ЮК ТА

ТУРИЗМ АВЫЛНЫ САКЛАП КАЛЫРГА БУЛЫША

Бөтендөнья туристлык оешмасы мәгълүматларына караганда, авыл туризмы дөнья буенча туризмны үстерүдә төп биш юнәлешнең берсе санала. Европа илләрендә ул популярлыгы буенча, пляж ялыннан кала, икенче урында. Шул рәвешле туриндустриянең 20-30 процент керемен алып тора. Россиядә агротуризмның потенциалы 50-60 миллиард белән исәпләнә, әмма ул 20 процентка гына кулланыла. Агротуризм бигрәк тә Иркутск өлкәсендә (анда 210 авыл туризмы объекты бар), Калуга өлкәсе (115) һәм Алтай краенда (110) үсеш алган. Авыл туризмы Франция, Бөекбритания, Голландия, Ирландия, Германия, Испаниядә авылны социаль-икътисади яктан үстерү программасының бер элементы булып тора. Татарстан агробизнес кадрлары белемен күтәрү институтының укыту-методик эшләр буенча проректоры Элеонора Хафизова фикеренчә дә, агротуризм авылны саклап калырга, сала кешеләрен эшле итәргә булышыр иде. Авылларда кече фермер хуҗалыклары да аякка басар иде. Моның никадәр мөһим булуын күздә тотып, институт быел авыл туризмы белән шөгыльләнергә теләүчеләр өчен махсус курслар ачкан.

– Узган ел 30 кеше өчен семинарлар оештырдык. Әмма бу эшнең никадәр җитди һәм күләмле булуын аңлаганнан соң, бер еллык курслар ачарга булдык. Яңа елдан 14 кеше шул курсларда укый башлады. Яңа эшкә тотынганчы, кеше күпмедер мәгълүматка ия булырга тиеш. Кунакханә бизнесы, туризм турындагы законнарны белүләре шарт. Юридик, икътисади, идарә итү, хезмәт иминлеге таләпләре, янгынга каршы тору чаралары, санитария-гигиена нормалары һәм кагыйдәләре, салымнар, җирләрне рәсмиләштерү һәм башка бик күп мәсьәләләр килеп баса алар алдына. Белемнәре булу – бер шарт. Тик эш башларга акчасы да кирәк. Аларга ниндидер ярдәм күрсәтүләрен сорап, моның өчен махсус закон булдыруны сорап, Дәүләт Советына да мөрәҗәгать иттек. Әлегә исә авыл туризмы белән фәкать энтузиастлар шөгыльләнә, – дип сөйләде ул безгә.

ЗАКОННАР КИРӘК

Питрәч районы фермеры Марсель Хәйруллин нәселле атлар үрчетү белән шөгыльләнә. Туристлар өчен атта йөрергә маршрутлар да эшләп куйган. Атта йөрергә өйрәтүче инструкторы да бар. Марсель Хәйруллинның агротуризмны үстерү теләге бар, әмма моңа мөмкинлекләр юк. Авыл хуҗалыгы җирләрендә туристлар өчен кунак йорты төзеп булмый. Дөресрәге, моңа рөхсәт бирә торган закон юк.

– Фермер йорты, хезмәткәрләр йорты, инструктор йорты төзелде. Аларны төзергә рөхсәт бирелсә дә, соңрак моның өчен җаваплылыкка тарттылар. Авыл туризмын үстерү өчен иң элек законнар булдырырга кирәк. Финляндиядә минем бер танышым шулай ук атлар тота. Урман эчендәге аланда кунак йорты төзегән, моңа беркем бернәрсә әйтми, әйтә дә алмый, чөнки аны закон яклый. Комплексына 12 чакрым асфальт юл салып куйганнар. Мөмкинлекләр бар, эшлә генә. Ә бездә бер дә уйламаган җирдән проблемалар чыгып кына тора, – ди ул.

Баулы шәһәренең «Салават күпере» ял һәм туризмны оештыру үзәге директоры Зөлфия Латыйпова фикеренчә дә, туристларны җәлеп итү өчен иң беренче чиратта инфраструктура булырга тиеш.

– Авылны күрергә, гадәттә, шәһәр кешеләре килә. Аларны кунак йорты, душ, бәдрәф булу-булмау кызыксындыра. Авылларда моны булдыру шактый чыгымлы эш. Моңа дәүләттән ярдәм каралмаган. Икенче проблема дип мин туристларны каршы алу культурасы булмауны әйтер идем. Экскурсоводлар җитми безгә. Авылдагы һәр чишмә, тауның үз легендасы бар. Авыл атамаларының барлыкка килү тарихы да кызыклы. Шуларны матур итеп сөйли белүче юк. Чит төбәкләргә баргач, безгә нинди генә кызыклы әйберләр сөйләмиләр. Булганмы ул, юкмы, без авызыбызны ачып шаккатып тыңлап торабыз. Мондый бал бездә генә дигән булып, берәр чәй кашыгы бал каптыралар. Бездә юкмы ул бал, безнеке тәмлерәк тә әле. Ә шуны бренд итеп күрсәтә белмибез. Бездә дә үсә тәмле, хуш исле үләннәр. Нишләп аларны күрсәтмибез. Бу – белемебез сай булудан. Авыл туризмы белән шөгыльләнергә теләүчеләр өчен Казанда курслар бар, әмма безнекеләргә анда барып йөрү җайсыз. Казан бездән 360 чакрым ераклыкта урнашкан. Районнарны зоналарга бүлеп, бирегә үзләре килеп укыта алмаслармы икән? Авыл туризмы бездә яралгы хәлендә генә. Ә аны үстерү өчен дәүләтнең ярдәме кирәк. Республикабыз агротуризм өлкәсендә бик перспективалы өлкә югыйсә, – дип сөйләде безгә Зөлфия Латыйпова.

Сүзен-сүзгә

Илнар Габдрәхимов, Теләче:

– Без кошчылык белән шөгыльләнәбез. Казлар, үрдәкләр, бытбылдыклар, ау фазаннары үрчетәбез. Фермерлык эшеннән кала, авыл туризмы белән дә шөгыльләнергә уйладык. Дәүләттән фермер буларак 1,5 млн сум грант алдык. Бу эшкә алынганчы Краснодар, Төмән, Екатеринбург, Тобольск, Сыктывкар һәм башка шәһәрләргә барып, аларның тәҗрибәсен өйрәнеп кайттым. Минемчә, авыл туризмы ул бер-ике сәгатьлек программадан гына тормый, көне буена яки берничә көнгә сузылырга тиеш. Ике сәгатьтә авыл һавасын рәхәтләнеп сулап та калып булмый. Хәзер күпләр, шәһәр ыгы-зыгысыннан арынып, берничә көнгә табигатьтә яшәп алырга кызыга. Шул төр ялның популярлаша баруын истә тотып, 20 елга арендага 50 гектар җир алдым. Бирегә килүчеләр күлдән балык та тота, көймәдә дә йөри, җиләк-гөмбә дә җыя алачак. Утын ярып, чишмәдән суын алып ашарга пешерә. Рәхим ит, мунча ягып кер. Теплицада, түтәлләрдә яшелчә үсеп тора. Кош-корт та аулый алачак. Суыткычларда сөте, эремчеге, күкәе – экологик чиста продуктлар торачак. Кирәк булса, киткәндә дә үзе белән алып китә ала. Казын да, үрдәген дә суеп бирәбез. Бала-чагага кызык булсын өчен кәҗәләр, атлар тотачакбыз. Кыскасы, ашык-пошык йөрмичә генә, үз өеңдә кебек ял итү урыны булдырасым килә.

***

Габделәхмәт Котдусов, «Татар страусы» туристлык комплексы (Биектау, Ямаширмә):

– Авыл туризмы белән шөгыльләнү өчен төп өч шарт бар. Аның берсе – туристлык комплексының Казаннан күп дигәндә 50 чакрым ераклыкта урнашуы. Икенчесе – ул авыл җирендә урнашкан булырга тиеш һәм өченчесе – бу эшкә теләк булу. Комплексыбыз Казаннан 45 чакрым ераклыкта урнашкан һәм шуның белән отабыз да. Узган ел безгә 7 мең турист килде. 2010 елда эшли башладык. Беренче елны 500 турист кунак булды. Баштагы өч елны минуска гына эшләдем, хәзер плюска эшлим. Чынлап торып кызыгып эшләсәң, авыл туризмы – бик перспективалы өлкә. Дөресен генә әйткәндә, миңа бу эш белән шөгыльләнергә фермер булуым ярдәм итә. Агротуризмны аның белән параллель рәвештә алып барам. Яңа эш башлаучыларга түгел, бу эштә азмы-күпме кыймылдый башлаганнарга ярдәм итәргә кирәк дип уйлыйм. Булганнарын үстерергә кирәк. Татарстан буенча авыл туризмы белән чынлап торып бер мин генә шөгыльләнәм.

Татарстанның Аграр яшьләр берлеге дә вакыйга туризмына игътибар итә башлады. Алар авылларда кызыклы чаралар үткәрә. Узган ел Питрәч районында беренче тапкыр «Скорлупино» йомырка фестивале узды. Анда иң зур йомырка тәбәсе әзерләнде. Йомырка атышып уйнадылар, зур йомырканы мәйдан буйлап тәгәрәттеләр, йомырканы шотландча да әзерләп карадылар. Быел ул 19 августта узачак. 29 июльдә Зәй районының Кадер авылында «Печәнфест» үтәр дип көтелә. Анда печән чабучылар, тракторчылар ярышачак. 12 августта Әгерҗедә «Пчелино» бал фестивален үткәрү каралган. Гыйнварның соңгы шимбәсендә Мамадышта «SunnyФЕСТ» чаналар фестивале үтәр дип көтелә. Республика Аграр яшьләр берлеге бәйрәмнәренә чакырып кала.

ЯЗМЫШ

Син булганда, без кадерле идек...

Якыннарны югалту кайгысы ничек кенә ачы булмасын, олы кешенең үз үлеме белән бакыйлыкка күчүен шулай тиеш инде дип кабул итәсең. 80не узган әбинең юл фаҗигасендә һәлак булуын ишеткәч, йөрәк сискәнеп куйды. Чуашия Республикасының Комсомол районы Урмай авылында гомер кичергән Фәхризиян Хәмдиеваның үлеме әнә шулай аянычлы була.

– Чабаксарга хастаханәгә барырга дип юлга чыккан идек. Әби, мин, рульдә әниемнең энесе Шамил абый һәм катлаулы операцияләр кичергән бер туганыбызның кызы белән. Әби гел алда утырып йөри торган иде. Бу юлы нигәдер мине алга утыртты. Акрын гына бардык. Әллә каян гына каршыбызга «Уаз-Патриот» машинасы килеп чыкты. Читкә дә чыгып беттек, фаҗигадән генә кача алмадык... – дип, күз яшьләре белән искә ала ул көннәрне Фәхризиян әбинең оныгы Гөлназ.

Каршыга чыккан машина хуҗасының кунактан кайтып килеше булган, ул йокымсырап киткән, диләр. Ике кешенең гомере өзелүгә сәбәпче булган адәм бер тапкыр килеп хәл дә белмәгән. Югыйсә Аллаһы аның үзен дә, янында утырган хатынын да саклаган, аларга берни дә булмаган.

Фәхризиян әби көр күңелле, яшенә күрә бик җитез була. Гел кунаклар җыйган, Коръән ашлары уздырган, бер ел да уразасын калдырмаган. Аның соңгы вакытта үзгәреп, моңсуланып китүен, һәр очрашкан кеше белән ризалык сорап, «исән-сау яшәгез» дип саубуллашуын олы кеше өчен гадәти хәл дип кабул итә якыннары. Инде менә хәзер фаҗигадән соң, Фәхризиян әбинең барлык әйткән сүзләрен искә төшереп, ул барысын да сизенгән, белгән, төш күргән булгандыр дип юрыйлар. Телевизордан бер юл фаҗигасе турында караганда, күршесенә бик борчылып, мондый язмышлар булмаса ярар иде, дигән. Соңгы вакытта гел, машинага утырырга куркам, дип тә әйтә торган булган. Үзенең күңелендә нинди генә күңелсез уйлар булмасын, балаларын, онықларын борчымаска, аларга сиздермәскә тырышкан. Авариядән соң Фәхризиян әби сигез сәгать яши. Соңгы сулышына кадәр оныгы Гөлназ, улы Шамил өчен борчыла.

– Мин китәм, риза-бәхил, балалар ни хәлдә, исәннәрме? – дип бәргәләнә ана.

20 май көнне Урмай авылында – Сабан туе. Фәхризиян әби алдан ук: «Мин быелгы Сабантуйны күрә алмам», – дип әйткән. Бик тә яратып, көтеп ала торган булган шул ул балаларының төп йортка җыйналуын. Бу – Хәмдиевләр гаиләсендә әнисез үтәчәк беренче Сабантуй. «Син булганда, без кадерле идек, бик бәхетле булып яшәдек», – дип язганнар балалары әниләренә багышланган бәеттә. Безнең бу язмабыз авылдашлары, туганнары, балалары өчен җан атып торган Фәхризиян әбинең рухына бер дога булсын иде.

Зөлфия ХӘЛИУЛЛИНА.

Ватан һәм ана...

САКАЛЛЫ КЕШЕ ЯЗМАЛАРЫ

Марат КӘБИРОВ

Бүген патриотизм турында сөйлиләр. Бу хисне арттырырга тырышып, төрле чаралар уздыралар.

Әлбәттә, патриотизм булырга тиеш. Кеше үз илен яратырга, аның куәтен һәм абруен күтәрергә, сакларга һәм кирәк икән – гомерен дә иле өчен бирергә тиеш.

Ләкин патриот булуның бер төп шарты бар – кешенең иле булырга тиеш. Ватаны.

Ватан ул туган җир, туган урын гына түгел. Бүгенге чорда кеше күктә дә туарга мөмкин.

Ватан-ана дигән сүз бар. Менә бу сүз Кеше һәм Ватан мөнәсәбәтен төгәл билгели шикелле: Ана һәм Бала мөнәсәбәте булырга тиеш. Һәм моның күзгә бәрелеп яткан берничә үзенчәлеге дә бар.

Мин «анам» дип әйткән кеше минем биологик анам булмаска да мөмкин.

Мин «анам» дип әйтү генә җитми, аның да «балам» дип әйтүе һәм кабул итүе кирәк.

Аның «балам» дию генә җитми, минем дә «анам» дип әйтүем һәм кабул итүем кирәк.

Ә безнең Ватан бармы соң?

* * *

Бу бер дә юктан туган сорау дип уйламагыз. Мин, әлбәттә, бик ялкау да, бик булдыксыз да кеше түгел инде. Эшләп тә торам, закон да бозмыйм, коткы таратып та йөрмим... Нәкъ сезнең кебек. Ләкин һәрвакыт шундыйрак бер тойгы бар. Ватан-Ана мәсьәләсендә. Ни өчендер мин үземнекен түгел, ә кемнеңдер анасын карыйм, тәрбиялим шикелле. Үзен Ватан-ана дип әйтүче бу хатын бөтенләй чит-ят булып тоела. Бәлки, ул үги анадыр? Ә бәлки, ул бөтенләй ана түгелдер, бала тапканга, бала ятканга бик охшап та тормый. Һәм ул безне дә үзенә бик кирәктә генә исенә төшерә. Шундый эгоист хатын.

* * *

Мине бүгенге Россия миллиардерларының күпчелеген өнәп бетермәүдә, гөнаһлы дип уйлауда гаеплиләр. Гафу итегез, әлбәттә. Аз гына онытып җибәргәнмен, алар нәрсә уйлап таптылар, нинди ачыш ясадылар, нинди юк нәрсәне бар иттеләр әле? Форд, Гейтс, Джобс, яки Безос диюгә, нәрсәдер күз алдына килә, шулай бит. Һәрхәлдә, боларның берсен дә карак дип тә, мошенник дип тә, спекулянт дип тә атап булмый. Ә безнең миллиардерлар исемен атауга, нәрсә күз алдына килә?..

Бер мисал. Менә сезнең әби-бабаларыгыз үз йортын саклау хакына сугышта үлеп кала, әти-әниләрегез шул йортны зурайту, матурлау өчен көнне-төнгә ялгап гомер буе тир түгә, ә бу эшем ияләре үз вазифаларыннан һәм вакытлыча бирелгән мөмкинлектән файдаланып, ялган документлар ясатып, сезне шул йорттан куып чыгара...

Йортның ни кысылышы бар? Кысылышы юк. Мин аны бары тик ата-бабалар бар иткән һәм баеткан ил-дәүләт символы буларак мисалга китердем.

Бу – сезнең үзегезне генә төп башына утырту түгел. Ата-бабаларыгызның да көче, байлыгы – шушылар кесәсендә, якты истәлеге – шушыларның табан астында. Чөнки сезнең Бөек Ватан сугышында батырларча һәлак булган бабаларыгыз ил өчен, балаларының киләчәге өчен җанын биргән герой түгел, ә нибары берничә каракны миллиардер итү өчен гомерен биргән фанат булып кына кала.

* * *

Теге дөньяга баргач, мин шул сугышта үлгән бабамның якасыннан алачакмын:

– Нигә үлдең, нигә исән йөреп кайтмадың? – диячәкмен.

Әлбәттә, ул акланган булыр:

– Шулай туры килде, сугыш каты иде.

– Ә ник бардың син анда?

Мондый сорауга ул ни дип әйтергә дә белмәячәк. Аның рухында түгел. Иленә дошман һөҗүм иткәндә, ничек итеп читтә калырга мөмкин булуын ул аңламый. Аның карашы, бүген моны без аңлыйбыз. Без!

– Син Гитлерны белә идеңме?

– Юк.

– Берәр немецны беләсеңме?

– Юк.

– Берәрсенең берәр зыяны тидеме сиңа?

– Юк.

– Шулай булгач, ник киттең ул яуга? Гомереңдә бер күрмәгән, бер белмәгән, үзеңә бер зыяны тимәгән кеше белән ник сугышып йөрдең? Ник үтердең аларны? Үзең ник үлдең?

* * *

Мин әле, сугыштан кайтмаганы өчен, урам буйлап ирләрен сүгеп йөргән берничә әбине үзем дә хәтерлим. Кечкенә идем ул чакта, өлкәннәр ул әбиләрне «зиһене дөрес түгел» диләр иде. Зиһене дөрес түгел... Гомер буена эчләрендә җыелып килгән рәнҗешләр бит инде бу. Илгә юнәлтергә ярамаган өчен ирләренә юнәлтелгән рәнҗешләр.

Мондый рәнҗешләр шул әбиләр белән бергә китсә, юкка чыкса, ни әйтер идең дә бит. Бер танышым бар. Гомерен хәрби хезмәттә үткәргән. Ватан куша диеп утка кергән, берничә тапкыр авыр яраланган. Катлаулы операцияләр кичергән. Исән калган. Даруларда яши. Бүген үндүрт мең сум пенсия ала. Инвалидлык буенча икенче группа да ала алмый йөри. Икенче группа! Моны бит инде вак-төяк чиновникларның бөтен туган-тумачасы, таныш-белеше алып бетерде. Ә моңа – юк.

Ну, ничек бирәсең инде аңа. Әнә ич фәлән танышның танышы Хәппениса карчык та инвалидлык сорап килгән. Аның яше дә зуррак, өстәвенә хроник рәвештә сул кулының уч төбе кычыта. Соң шулай булгач, бернинди эшкә дә ярамый бит инде ул. Өстәвенә, халык бәхете өчен Фәлән Фәләневичны үстереп биргән. Шундый кешегә бирмичә, ниндидер солдафонга бирәсеңмени ул инвалидлыкны?!. Аннан соң Хәппениса карчык берәү генә, ә болар – миллион. Берсенә бирсәң, калганнары сорый башлаячак. Эшләре беткән инде хәзер, шыбырдамый гына утырсыннар... Үзебезнең таныш-белешләргә дә җитеп бетми әле.

Менә шундый хәлләр.

Барысын да күреп торгач, бүген без төрле сәбәпләр белән сугыштан качып, үз җаен гына караган куркак җаннарны аңлыйбыз кебек. Бүген алар акыллырак, хаклырак кебек булып тоела.

* * *

Ватанлы кешеләр шулай була аламы?

Әгәр Ватан-ана бар икән, бүген аның мөлкәтен урлап баеган караклар әнисенең пенсиясен сатып эчкән алкаштан нәрсәсе белән абруйлырак?

Әгәр Ватан бар икән... Ата-ана хокукыннан нәрсә өчен мәхрүм итәләр әле ул? Балаларын бар дип белмәгән өченме?

Әгәр Ватан юк икән... Ничек югалган ул? Үтерганнәрме аны, урлаганнармы, сатып җибәргәннәрме... – юк, мондый сораулар белән баш катырырга җыенмыйм. Кирәкмидер дә. Барыбер дөресен әйтмиләр ич. Ә мине әлегә бер генә сорау борчый. Нибары бер сорау.

Әгәр Ватан юк икән, безгә – патриотларга нәрсә эшләргә?..

МӘҺДИЕВ ҺӘМ...

БӘЯН-ХАТИРӘ

Вакыйф НУРИЕВ

(Әсәрдән өзек)

→ **Ахыры. Башы 11 май санында.**

Миндә имтихан кайгысы бетте. Нигә кирәк Керенский-Меринскийлар, Капланнар-Мапланнар... Таһир, Нәфисә кебек халык бәгыреннән чыккан җырчылар авылга көн саен килеп тормый.

Концерт шәп булды. Халык клубка чак сыйды. Мәшһүрләр кич буена моң сипте. Хәлил Сәлимов университетның журналистика бүлегендә укучы Альберт Һадиев язган, бер абзыйның фронтта һәм мунчада күргәннәре турындагы хикәяләрне сөйләп эч катканчы көлдерде. Концерт барганда, клубның ишегеннән, бүрәнә ярыкларыннан пар чыгып торды.

Иртәгесен буран башланды. Юллары кар күмде. Имтиханга әзерләнү турында уйлыйсы да юк. Казанга ничек китәргә? Башта шул кайгы. Артистлар да китә алмады. Хәер, аларга борчыласы юк. Хәлил абыйны кунарга үзебезгә алып кайткан идем. Таһир Якуповны да чакырдык. Ашарга-эчәргә бар. Әни коштабак тутырып ит пешерде. Сыйланып тик ят. Иртәгесен клуб көн буена ачык булды. Халык яраткан артистларыннан аерыла алмады. Авылдашларым өчен бер бәйрәм булды бу буран. Минем генә кәеф юк. Имтиханга барып җитә алмасам, университеттан куарлар дип куркам.

Бер тәүлек дулаганнан соң, буран тынды. Мин, төнге өчтә торып, юлга чыктым. Артистлар йоклап калды. Бүген имтихан. Авылдан сигез чакрым ераклыктагы Мөндешкә карга бата-бата менәсе. Стансага җитәрәк, кечкенә генә Либәдән дип аталган зиреклекне үтәсе. Аны үткәндә, таң билгеләре беленә башлаган иде инде. Шулвакыт зиреклектән бүре атылып чыкты. Үзе бозау кадәр, башы атныкы кадәр. Хәл китте. Кулда таяк бар-барын. Өскә ташланса, ул таяк белән генә нишли алам мин?! Зиреклектән кинәт чыккан бүре кинәт кереп тә китте. Стансага килеп җиткәнче, адым саен артыма борылып карадым. Бүре бүтән күренмәде. Поездга кереп утырганда, хәлем тәмам беткән иде. Казанга килеп җиткәч, вокзал янында җиденче троллейбуска көтеп иза чиктем. Ул килмәгәч, университетка җәяү чаптым, югыйсә, имтиханга өлгермәячәкмен. Бураннан соң җылытты. Казанда кар эри. Тау менгәндә тирләдем-яндым. Авылдашым, ак тегүче Ибрай бабайның калын сарык тиресеннән тегеп биргән тунын салып ташлардай булдым. Мин килеп кергәндә, профессор Субич аудиториядә үзе генә иде. Ведомостьларны портфеленә салып маташа. Ни өчен соңга калуымны аңлата алган кадәр аңлатып бирдем. Ул миңа гаҗәпләнеп карап торды да билет алырга кушты. Алдым. Беренче сорау: «Думская тактика большевиков». Большевикларның Думада күбрәк урын алырга теләүләрен генә беләм. Шуннан артыгын әйтә алмыйм. Гомумән, мин нидер әйтерлек, сөйләрлек хәлдә түгел идем. Беренче имтиханда ук – «провал». Университеттагы соңгы имтиханым да шушы булыр. Хәзер тулай торакка кайтып әйберләремне җыям да авылга китәм. Фермада яки конюшнидә эшләмәслек егетме мин?! Мәктәпнең завучы Тәлгать абый: «Университетны тәмамлагач, авылга кайтырсың. Мәктәпнең стена гәҗитенә баш мөхәррир итеп куярбыз сине», – дип тә ышандырган иде. Бәлки, хәзер үк куярлар. Җитмәсә иртәнге бүре күз алдымда тора. Казанда, университетта калган тәкъдирдә ул минем каршыга тагын чыгачак. Төштән соң укыгач, мин авылдан дүшәмбе китәм. Бер төн булса да өйдә кунасы килә. Юлда үзем генә. Кемнең төнге өчтә торып китәсе килсен.

Тулай торакка кайтып әйберләремне тутыра башладым. Кулыма Мөхәммәт Мәһдиевнең «Фронтовиклар» китабын алгач, әллә нишләп киттем. Педучилищеда нинди михнәтләр күреп укыганнарын әни миңа сөйләгән иде инде. Ач булганнар – укуны ташламаганнар. Юлсызлыктан интеккәннәр – укуны ташламаганнар. Каршыларына бүреләр өере чыккан – укуны ташламаганнар. Син?.. Караватка утырдым да үз-үземне эттән алып эткә салдым. Мөхәммәт абыйның: «Имтиханны бер бирмәсәң, тагын кереп була бит аңа», – дип әйткән сүзе дә искә төште. Авылда минем турында, Мәһдиев аны университетка «по блату» кертте, дигән сүзләр дә йөри бит әле. Хәзер әйтәчәкләр: «Әһә, по блату» кергән иде, укый алмады. 1981 елда журналистика кафедрасы мөдире Флорид Әгъзәмов «Социалистик Татарстан» (хәзер – «Ватаным Татарстан») газетасының 19 ноябрь санында минем турында язып чыккач, «по блату»ны авыл бөтән әйтмәде. Язмада мондый юллар бар иде: «Туган төбәгендә борын төрткән һәр сәләтле егет-кызга утә игътибарлы, журналист җанлы Мөхәммәт Мәһдиев тә әлеге абитуриентка «өметле, тырыш егет» дигән бәя бирде».

«Фронтовиклар»ны «Казан утлары» журналыннан укыган идем инде. Хәзер китабын укыйм. Аны, портфелемә салмыйча, кире шүрлеккә куйдым. Мин университетта калырга булдым. Дүрт көннән соң Субичка имтиханны тапшырдым. «Бишле»лек сөйләдең, «дүртле» куям, чөнки «пересдача» бит, үзең беләсең», – диде профессор.

Либәдән зиреклегеннән чыккан теге бүре исә станса мичәнә ягучы Галимҗан абзыйның эте булып чыкты».

СЕЗ КАЙЛАРДА, ЙОЛДЫЗЛАР?

Без кайчандыр бик популяр булып, соңгы елларда бик сирәк күренгән яки бөтенләй югалган җырчыларны барладык. Аларны, шартлы рәвештә, ике төркемгә бүлеп карарга мөмкин булыр иде. Бер ишләре (Эльвира Розали, Сәнифә Рангулова, Виталий Агапов, Гөлнара Тимерҗанова, Эльвира Хәйруллина, Лилия Хәмитова, Сәгыйть Гыйбашев) киң җәмәгатьчелеккә сирәгрәк күренсә дә, тамашачы белән элемтәләрен бөтенләй югалтып бетергән дип әйтеп булмый. Икенчеләре тормышларын тамырдан үзгәртеп, бөтенләй башка өлкәдә хезмәт куя. Дөресен язарга кирәк, төрлесе төрле тарафка таралышкан җырчыларны эзләп табу җиңел булмады. Шуңа күрә кайберләре турында мәгълүмат бөтенләй туплый алмадык. Мәсәлән, «Әнием, әнием, гөлләр үстерәм сиңа» җыры белән танылган Энҗе, «Миләшкәем, хәлең ничек?» дип моңланучы Зөлфия Минһаҗеваның бүген ниләр белән шөгыльләнүен ачыкларга насыйп булмады. Эзләп тапканнарының да берничәсе, журналист иҗәнлегебезне белгәч, сөйләшергә теләмәүләрен белдерде. Ә элемтәгә чыга алганнары безгә менә нәрсәләр турында сөйләде.

АЛКЫШЛАР

Зөһрә САДЫЙКОВА

ГӨЛНАРА ТИМЕРҖАНОВА: «ҮЗЕМНЕ КЫЗЫМНЫ ТӘРБИЯЛӘҮГӘ БАГЫШЛАДЫМ»

Популяр җырлары: *«Йолдызлар яңгыры», «Мәхәббәт ялкыны», «Өйдә буран булмасын».*

Иң актив иҗат иткән чоры: *2000-2012 еллар.*

Хәзерге көндә эшләгән урыны: *«Гөлнара» җыр театрының солисты һәм җитәкчесе.*

– Айзифаны алып кайтканнан соң, бөтен барлыгымны кызымны тәрбияләүгә багышладым. Аннан соң, әледәнәле яңа җырлар ишетеп торгач, тамашачы да арый, кабул итми башлый дип уйлыйм. Шуңа күрә үзем дә, халык та минем иҗаттан ял итеп алды, инде масштаблы рәвештә яңа җырлар яздырырга вакыт җиткәндер дип саныйм, - диде җырчы.

СӘНИФӘ РАНГУЛОВА: «ОНЫТЫЛАБЫЗ ШУЛ»

Популяр җырлары: *«Елмай», «Кызлар пирчәткә түгел».*

Актив иҗат иткән чоры: *1995-2000 еллар башы.*

– Хәзерге вакытта, сирәк кенә булса да, җырлар язам. Киләсе атнада Арча районының Түбән Аты һәм Гөберчәк авылларына сольный концертларым белән барырга уйлыйм. Районнарга күптән чыкканым юк иде. Соңгы елларда бары ике-өч тапкыр барырга туры килде. Соңгы тапкыр сольный концертымны ун ел элек эшләгән идем. Аны телевизордан да еш күрсәтеләр. Сату-алу тармагында эшләп караган идем дә – күңелемә ятмады. Гомумән, иҗаттан бөтенләйгә аерылганым да булмады үзе. Ә соңгы берничә елда күренмәвем миннән генә тормый. Замана үзгәргәндер бәлки. Телевидениедән җырчы күренмәсә, алда эшләгән еллары турында онытыла башлый шул, – диде Татарстанның атказанган артисты Сәнифә Рангулова.

ЭЛЬВИРА РОЗАЛИ: «ТОРМЫШЫМНАН КАНӘГАТЬМЕН»

Популяр җырлары: *«Бәхет нигә ерак?», «Ал мине үзең белән».*

Иң актив иҗат иткән чоры: *1990-1996 еллар.*

Хәзерге көндә эшләгән урыны: *2006 елдан Казан дәүләт мәдәният институтының соло җырлау кафедрасында хезмәт итә һәм балалар белән эшли.*

